# Түгәрәк уен

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ

3 / 2020

«Ак калфак» – милли киемнең татар мәдәнияте символикасына әверелгән матур бер өлеше. Сүзтезмәдәге «ак» сүзе баш киеме тегелгән тукыманың ачык төсен генә күрсәтеп калмаган, чигештәге көмеш ука җепләрнең якты җемелдәвен дә аңлаткан












Дмитрий Петриченко фоторәсемнәре



Ирада ӘЮПОВА,
Татарстан Республикасы Мәдәният министры:

# «МИЛЛИ КИЕМ тирәлегебезнең бер өлешенә әверелсен иде»

**Мәдәният йөзсез була алмый – бу минем уйлаганымнан кайтмый торган ныклы фикерем. Мәдәният теге яки бу мәдәни код формалашкан җирлекнең үзенчәлекләрен сакларга тиеш. Унификация, чикләрнең юылуы һәм бертөрлелеккә омтылыш тормышның төссезләнүенә китерәчәк.**

Мин милли киемнәрне һәм милли аш-суны бик яратам. Әйтик, ял көннәрендә гаиләмне милли ризыклар белән сыйларга тырышам: бәлеш, кыстыбый, өчпочмак пешерәм – фатирга традицион татар ашларының тәмле исе таралырга тиеш. Милли кием – алкалар, читекләр, изү, хәситә һәм башкалар белән мин үземнең милли үзенчәлегемне күрсәтә алам һәм мин моның белән горурланам.

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургалиевич Миңнеханов матбугатта басылган мәкаләсендә сувенир халыкка әверелмәсәк иде, дигән фикер үткәрде. Уйлап карасаң, монда бик нечкә фикер ята.

Мине халык гамәли сәнгате белән сувенирлар җитештерүне тәңгәлләштереп карау кимсетә. Сувенир ул – тиражланган продукция. Тамырында халык сәнгате ятса да, аның үзкыйммәте тиражлаган аппаратура бәясеннән тора. Бу – массмаркет. Ә бит безнең рухка туры килгән эксклюзив әйберләр бар. Алар безнең үзенчәлекне ассызыклаячак. Монысы инде халык гамәли сәнгате. Бу сувенир түгел, бу иҗат. Без кешеләргә көндәлек киелә торган милли киемнәр дә тәкъдим итәргә тиешбез. Аларның бәясе дә кеше алырлык булырга тиеш, әлбәттә. Әлеге милли киемнәрне күренекле шәхесләр киеп, халыкка үрнәк күрсәтергә тиештер.

Без хәзер мәдәнияттә яшәү рәвеше турында сөйләшә башладык. Мәдәният ул вакыйга гына түгел, мәдәниятне ниндидер мәдәни чараларга кайтарып калдыру да дөрес түгел. Мәдәният – көндәлек экосистема, ул – безнең тирәлек. Милли киемнәр шушы тирәлекнең бер өлешенә әверелсен иде.

**(«Алтын хәситә» Халыкара конкурсы уңаеннан журналистлар белән очрашу вакытындагы чыгышыннан)**

# Түгәрәк уен

№ 3 2020

16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

Гамәлгә куючылар:
Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгы каршындагы
Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге

Редколлегия:
Ирада Әюпова
Марсель Бакиров
Разил Вәлиев
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов

Директор: Алсу Равил кызы Мифтахова
Баш мөхәррир: Рәзинә Әхтәм кызы Исмәгыйлева

Альманахның иҗат төркеме:
Гөлназ Латыйпова
Рәмзия Гайфетдинова
Сөмбелә Вәлиәхмәтова
Илнара Гәрәева

Дизайнер һәм биткә салучы: Диләрә Нәүрузова

Альманах 2020 елның 13 ноябрендә элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79590. Журнал өч айга бер чыга. Бәясе ирекле.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛. Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 30.09.2020
Чыгу көне:

Заказ:
Тираж: 1000 экз.

Редакция һәм нәшер итүче:
420021, Казан, Тукай ур., 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин ур., 66/33
Телефон: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru

«Визарт» ҖЧҖндә бастырылды.
Казан, Җиңү проспекты, 78

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый. Күчереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.

**Тышлыкта:** 19 йөз ахыры – 20 йөз башындагы калфак бизәге

© «Түгәрәк уен», 2020

*Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,*
*моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.*
*Г. Тукай*

**ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕ ЯҢАЛЫКЛАРЫ**

4 **Гөлбикә белән Гомәр бакчага китте**
**Сабантуй үткәрергә онлайн өйрәтәләр**
**Онлайн бәйрәмнәр**
**«Алтын хәситә» – милли кием бәйгесе**
**Татарстанда «Uen fest» фестивале старт алды**
**Казан-Кырым арасы**

**ТАССРның 100 ЕЛЛЫГЫ**

10 Л. Мөхәммәтова
**«Гармуныңны тартып уйна...»**

**ХАЛКЫМНЫҢ ОСТА КУЛЛАРЫ**

16 Л. Саттарова
**Ак калфак**

**ЙОЛА**

22 З. Бруськo
**Бәби мунчасы саваплы була: татарларның бала коендыру йоласы**

**ӘДӘБИ МИРАС**

25 Г. Гыйльманов
**Халык иҗаты каян башлана яки Исәнбәт васыяте**

28 Л. Мөхәммәтҗанова
**Татар эпосы нинди ул?**

**БӨЕК ҖИҢҮГӘ – 75 ЕЛ**

31 Р. Хөсәенова
**Кызыл олау**
*(Фольклор-хореографик композиция)*

**МИЛЛИ УЕН КОРАЛЛАРЫБЫЗ**

34 Г. Макаров
**Дәверләрдән килгән дәф**
*(Татар халкының иң борынгы бәрмә уен коралы дәфкә фәнни караш)*








**МУЗЫКАЛЬ МИРАС**

37 Н. Яхина
**Музыкаль фольклористика – музыка сәнгатенең нигезе**

**ХӘТЕР-ХАТИРӘ**

39 А. Гайнетдинов
**«Нократ маҗаралары»**

**ҺӨНӘРЛЕ ҮЛМӘС...**

44 С. Вәлиәхмәтова
**Каюлы күн дәресләре**

**БЕЗНЕҢ КИТАПХАНӘ**

48 **Себер – дастаннар иле**
**Ак Күбәк** *(Дастан)*

**БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...**

53 **Балалар иҗаты**

56 З. Шәфигуллина, Н. Гайфуллина
**Күзге муллыкны эзләп . . .** *(Квест-уен)*

59 **Алма җыябыз** *(Җыр)*

**ӨЙ КҮРКЕ – АШ**

60 **Бәрәңге тәкәсе**

**ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ**

64 **Шахворд**

## ГӨЛБИКӘ БЕЛӘН ГОМӘР БАКЧАГА КИТТЕ

**Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге заказы белән милли костюмлы, татарча сөйләшә торган 4 меңгә якын курчак эшләнде. Экологик чиста материалдан ясалган Гөлбикә белән Гомәр исемле әлеге курчаклар Татарстандагы барлык 1992 балалар бакчасына таратылды.**

Курчаклар Киров өлкәсендәге «Весна» уенчыклар фабрикасында эшләнде. Алга таба алар, фабриканың каталогына кертелеп, сатуга да чыгачак.

Әлеге уенчыкларны җитештерү идеясы белән курчаклар ясаучы дизайнер Эльза Хөснетдинова чыккан иде. Курчаклар ясату өчен Татарстан Президенты 6,9 млн сум акча бүлеп бирде.



## САБАНТУЙ ҮТКӘРЕРГӘ ОНЛАЙН ӨЙРӘТӘЛӘР

**Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге Бөтендөнья татар конгрессы белән берлектә ел саен Сабантуй үткәрүчеләр өчен курслар оештыра. Быелгы укулар 8-18 июнь көннәрендә онлайн форматта Zoom, YouTube, Instagram мәйданчыкларында барды. Курс дәвамында 21 лекция, алты осталык дәресе һәм өч иҗади очрашу узды**.

Онлайн курсларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе, Казан дәүләт мәдәният институты, Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге белгечләре, Республиканың Керәш федерациясе, Санкт-Петербург дизайнерлар берлеге вәкилләре дәресләр бирде.

Әлеге онлайн-курсларга 480 кеше язылды. Алар арасында 19 илнең татар диаспорасы вәкилләре бар иде. Болар – Австралия, Бельгия, Болгария, Чехия, АКШ, Германия һәм башка илләрдәге милләттәшләребез. Актив тыңлаучылар булarak, Россия Федерациясенең 34 регионыннан һәм Татарстанның 27 районыннан вәкилләр катнашты.

Видеоязмалар социаль челтәрләрдә дә актив каралган: @tatfolk ның төрле социаль челтәрләрдәге рәсми аккаунтларында видеоязмалар белән 33 818 кеше танышкан.

## ОНЛАЙН БӘЙРӘМНӘР

**Билгеле сәбәпләр быелгы күп кенә мәдәни чараларны онлайн форматка күчерергә мәҗбүр итте. Шул исәптән, елның-елында уза торган халык бәйрәмнәре дә онлайн узды.**

Онлайн Сабан туен (4 июль) 636 027 кеше караган. «Каравон» рус халык бәйрәмен (23 май) – 982 717, «Семык» мари мәдәнияте республика бәйрәмен (5 июнь) – 179 278, «Балтай» мордва мәдәнияте республика бәйрәмен (14 июнь) – 18 028, «Гырон быдтон» удмурт мәдәнияте республика бәйрәмен (27 июнь) – 153 385, «Иван Купала» славян мәдәнияте республика бәйрәмен (5 июль) – 37 398, «Уяв» чуваш мәдәнияте республика бәйрәмен (11 июль) – 242 568, «Питрау» керәшен мәдәнияте республика бәйрәмен (18 июль) 352 567 кеше тамаша кылган.




## «АЛТЫН ХӘСИТӘ» – МИЛЛИ КИЕМ БӘЙГЕСЕ

**Казанның Каюм Насыйри урамында корылган ачык сәхнәдә быелның 29 августында «Алтын хәситә» милли костюм Халыкара конкурсының финалы үтте.**

Конкурс җиңүчеләренә тантаналы шартларда коллекция әзерләү өчен сертификатлар тапшырылды һәм остазлар билгеләнде. Остазлар арасында модельерлар Надежда Әюпова, Изольда Сахарова, ювелир Рәфкать Мөхәммәтшин кебек милли мода өлкәсендә танылган шәхесләр бар иде.







Конкурста катнашучылар алты номинация буенча көч сынашты: «Реконструкцияләнгән тарихи милли костюм», «Сәхнә милли костюмы», «Заманча авторлык костюмы» (Casual), «Балалар милли костюмы», «Баш киеме һәм аксессуарлар», «Милли киемле курчак». Премия фонды – 3 600 000 сум.

«Без киләсе елга җиңүчеләребезнең коллекцияләрен халыкка тәкъдим итәргә планлаштырабыз. Хәзер алар иҗади төркемнәргә берләшеп, грант хисабына коллекция әзерли башлый. Без аларга әлеге костюмнарны Халыкара конкурсларга тәкъдим итәргә булышачакбыз», – диде Татарстанның мәдәният ресурс үзәге җитәкчесе Алсу Мифтахова.

Җиңүчеләр: Хәмидә Иноятова, Луиза Фәсхетдинова, Солтан Салиев, Ирина Әхмәтшина, Гөлфия Шәйдуллина, Гөлназ Афанасьева, Ольга Родионова, Әлфия Артемьева, Ольга Леуштан, Анастасия Асонова, Анастасия Волкова, Таңсылу Гыймадиева, Зәлинә Хафизова.

Рәйсә Сафиуллина фоторәсемнәре

## ТАТАРСТАНДА «UEN FEST» ФЕСТИВАЛЕ СТАРТ АЛДЫ

**Быелдан традицион халык уеннарына һәм күңел ачуларына багышланган «Uen fest» беренче фестивале старт алды. Фестивальне республиканың дәүләт театрлары актерлары, мәдәният йортлары хезмәткәрләре, Казан дәүләт мәдәният институты студентлары башлады – алар халык уеннарын видеога яздырып #уенфест хештэгы белән үз учреждениеләренең социаль челтәрләренә урнаштырды. Дәүләт театрлары актерлары Казан ишегалларында балаларга борынгы уеннарның барлыкка килү тарихын сөйләп, барлык теләүчеләрне дә уйнарга өйрәтә башладылар.**

«Виртуаль дөньяда яшибез, өлкән буын гореф-гадәтләрне күпмедер дәрәҗәдә белсә дә, яңа буын традицияләребезне белмәүдән, аралашу булмаудан интегә. Бергәләшеп уеннар уйнау бер-береңә ышанычны арттыра, гаиләне берләштерә, уңай хис-кичерешләр тудыра», – диде Татарстан Республикасы Мәдәният министры Ирада Эюпова конкурсны тәкъдим иткәндә.

1 августтан фестивальнең конкурс өлеше башланды. Фестивальдә катнашу өчен бөтен республикадан ишегалды командалары чакырылды, катнашучыларның яше чикләнмәгән. Финалистлар видеоязмалар аша билгеләнәчәк. Оештыручылар җиңүчеләргә кыйммәтле бүләкләр вәгъдә итә.



Фоторәсем Г. Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театры архивыннан

## КАЗАН-КЫРЫМ АРАСЫ

**Татарстанда «Солхат утлары» регионара проекты кысаларында Кырым рәссамнары һәм һөнәрчеләре булып китте. Декоратив-гамәли сәнгать осталары арасында агачны, күнне сәнгати эшкәртүчеләр, алтын җепләр белән чигүчеләр, керамика, батик белән эш итүчеләр бар иде.**




Татарстанга килгән Кырым рәссамнары һәм һөнәрчеләре Казан музейлары һәм уку йортлары белән танышты, шулай ук, Арчаның «Казан арты» тарих-этнография музеенда, Балалар сәнгать мәктәбендә, Кырлайда Г. Тукай Дәүләт әдәби-мемориаль музей комплексында, Балтач районының Чепья авылында урнашкан «Халыклар дуслыгы» туган як тарихы музеенда булдылар, Яңгул авылында тал чыбыктан үреп эшләнгән җиһазлар җитештерүче «Ива Мебель» фабрикасы белән таныштылар.

Кунаклар ТАССРның 100 еллыгы уңаеннан, быелның 29-30 августында Казанда оештырылган милли бәйрәмнәрне үз иттеләр: «Печән базары»нда, «Уйнагыз, гармуннар!»да, «Түгәрәк уен»да катнаштылар. Татарстан халкы өчен осталык дәресләре дә бирделәр.

Алтын куллы Кырым осталарының сәнгать әсәрләре Татарстан халыклары Дуслык йортының күргәзмәләр залына куелды. Биредә ай дәвамында Кырым сәнгать әһелләре күргәзмәсе эшләде.

«Солхат утлары» регионара проектының төп вакыйгасы быелның 25 ноябрендә Симферопольдә көтелә. Биредә ике республиканың рәссамнары һәм декоратив-гамәли сәнгать осталарының уртак күргәзмәсе ачылачак.

Солхат – Кырым ханлыгының борынгы башкаласы исемнәренең берсе. «Солкат» топонимы шәрыкъ, көнчыгыш мәгънәсен бирә.








**Кырым осталары – Татарстанда**

Рәйсә Сафиуллина фоторәсемнәре













**Татарстан халыклары Дуслык йортында Кырым осталарының сәнгать әсәрләре күргәзмәсе ачылу тантанасыннан күренешләр**










Дмитрий Петриченко фоторәсемнәре

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

***Тальян – гармуннар гаиләсенең иң күренекле вәкиле буларак билгеле. Әлбәттә, бу гаиләдә аның башка туганнары да яши. Алар арасында «Саратов гармуны» да, даны шактый ерákларга таралган «хромка» да бар. Алар бер-берләреннән кайсы яклары белән аерылалар соң? Шушы сорауга җавап биреп карыйк. Гармуннар нинди генә төрдә булмасыннар, аларның һәркайсы өч өлештән: уң һәм сул як планкалардан, күректән тора. Планкалардагы төймәләренең саны, урнашу тәртибе, күректәге һаваны тиешле вакытта ничек, нинди җайланмалар белән өрдереп булуларына карап, аларны аералар да инде.***

# «ГАРМУНЫҢНЫ тартып уйна...»



Фоторәсем Айрат Харисовның шәхси архивыннан

***Тальян гармунның уң як планкасында бармакчыклары (озынча төймәләре) була. Ә сул ягына өч кенә төймә урнаштырылган. Сул як төймәләрне халкыбыз аваз чыгарудагы роленә бәйле, бик үзенчәлекле итеп, «бака» дигән исем белән йөртә. Тальян гармунда уйнаучылар, үзләренең теге яки бу көйне башкару серләрен чишә башласалар, төп игътибарны нәкъ менә шушы бакалар урнаштырылган якка бирәләр дә инде. Моның да үз сәбәпләре бар. Чөнки аның иң өстәге төймәсе – аккорд бирү өчен, астагысы – бас партиясен башкара, ә уртадагысы – авазны педальли. «Бака»лы якның тагын бер сере – планканың астында урнашкан, һаваны авазсыз гына чыгару төймәсенең булуы. Бу төр татар гармуннарының уң як планкасындагы бармакчыкларының (төймәләренең) саны уннан алып уникегә кадәр булырга мөмкин. Көйнең төп партиясен, шушы планкадагы бармакчыкларга басып, андагы телләр аркылы күрек ярдәмендә һава агымын өрдереп уйныйлар да инде. Уң як планка өстендә биш, кайвакыт алты данә регистр урнаштырылган. Алар да – татар гармуны яңгырашын башка гармуннардан аерып торган үзенчәлекле механизмнарның берсе. Әлеге регистрларның төп вазыйфасы – уйналасы көйгә бәйле рәвештә гармун авазының тембрын үзгәртү, шуның бәрабәренә көйнең ятышлылыгын, аһәңен арттыру, моңын бирә белү. Менә шушы үзенчәлекләре булганга татар гармуннары арасында иң мәртәбәле урынны тальяннар алып тора да инде.***

**(Гармун, кубыз, курай... Балалар өчен аудиокушымталы һәм фотоиллюстрацияле китап (Татар халык музыка уен кораллары) / Ф.Х. Җәүһәрова, Г.Г. Гыйлемҗанова, Д.А. Габдрахманов. – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2019. – 64 б., фотолар б-н.)**

## «ТАЛЬЯН ГАРМУН – ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ВИЗИТ КАРТОЧКАСЫ»

Халкыбызның милли моңнарын тальян гармуннан башка күз алдына да китереп булмый. Әмма фольклор фестивальләрендә, музыка бәйгеләрендә, Сабантуйларында сәхнә күрке булып торса да, тальян гармун тормышыбыздан китеп, кирәге бетеп бара.

Гармунда уйнаучылар бар әле, ләкин аны ясаучылар юк диярлек. Бүгенге көндә Казанда яшәүче Айрат Харисов – Татарстан белән Башкортстан республикаларында бердәнбер профессиональ дәрәҗәдә гармун ясау һәм төзәтү остасы. Тумышы белән ул Башкортстанның Борай районы Кәшкәләү авылыннан. Казанга исә үзен гармун ясау эшенә тулаем багышлар өчен күченеп килә.

Узган 2019 елда Татарстан Республикасы Президенты тәкъдиме белән аңа 100 тальян гармун ясарга заказ бирелгән иде. «Мин Казанда узган Татар эшмәкәрләре җыены уңаеннан оештырылган күргәзмәгә гармуннар куйган идем. Әлеге күргәзмәгә килгән Президент Рөстәм Миңнеханов минем гармуннарны карады да: «Авыл клубларын да татарның милли инструменты белән тәэмин итәргә кирәк», – дигән фикерен җиткерде. Проект шуннан башланып китте. Тальян ул татар җырының төзелешенә, пентатоникасына туры килә. Шуңа күрә татар халкы тальянны яратып, үзенеке итеп кабул иткән. Без аны, татар халкының визиткасы,



**Гармун ясау остасы Айрат Харисов**

дия алабыз. Әмма тальянны татар халкының музыка уен коралы дисәк тә, сәхнәдә сирәк күрәбез. Башкортстан, әнә, курайны югары дәрәҗәгә күтәрде. Курайчылар сәнгать академияләрендә укытыла. Зур кунакларны курайчылар каршы ала. Ә без тальяннан шундый бренд ясый алыр идек», – дип искә ала Айрат әфәнде ул сөйләшүне.

Проект кысаларында ясалган тальяннарның унысы былтыр ук Республика көнендә иясләренә бирелде. Ә ТАССРның 100 еллыгын каршылаган көннәрдә гармуннар ясау остасы Айрат Харисов республикага 100 тальян гармун ясап тапшырды.



**«Әүлия моңнары» ансамбле. Сарман районы Иске Минзәләбаш авылы**

Рәмзия Йөзлебаева фоторәсеме

## «АЛДА ТАЛЬЯННАН БРЕНД ЯСАУ МАКСАТЫ ТОРА»

«Без әлеге гармуннарны ел дәвамында Балалар сәнгать мәктәпләренә, мәдәният йортларына, безнең республика программалары буенча төзелгән клубларга тапшырып, тальянны алучыларның ничек шатлануларын күрдек.

Әлеге проект тальян остасына эшен киңәйтеп җибәрергә дә мөмкинлек бирде. Киләчәктә без тальянчылар конкурсы оештыра алабыз. Тальян соңгы вакытта онытыла башлаган иде. 100 тальянда 100 кеше уйнарга өйрәнсә дә, аларга карап яшьләр тартыла башлар. Безнең алдыбызда тальяннан бренд ясау максаты тора», – ди Татарстан Республикасының Мәдәният министры урынбасары Ленар Хәкимҗанов.

## БУ ПРОГРАММА ДӘВАМ ИТСӘ, ИКЕ-ӨЧ ЕЛДАН НӘТИҖӘСЕН БИРӘЧӘК

«Республикада милли татар инструментлары популяр түгел, аларга ихтыяҗ бетеп бара. Милли инструментларда бабайлар һәм эстрада артистлары гына уйный, дип гел борчылып йөрдем. Проблемалар күп. Бездә, беренчедән, республикада тальянда һәм гармунда уйнарга өйрәтә алучы укытучылар юк. Икенчедән, тальянда һәм гармунда уйнарга өйрәтү программасы юк. Өченчедән, балалар өчен педагогик репертуар бик сай. Дүртенчедән, гармунчылар конкурсларында һәм фестивальләрендә гармун уйный белгән балалар юк дәрәҗәсендә, аларның катнашуы сенсациягә тиң. Бишенчедән, музыка мәктәпләрендә тальяннар, гармуннар юк.

Узган ел 30 августта без Татарстан Президенты бүләге буларак, беренче тальяннарны алдык. Безнең Балалар сәнгать мәктәбенә бүләк ителгән тальянны бик талантлы бер кызыбызга тапшырдык. Венера Залятова минем тальянчылар ансамбленә йөри. Ул әбисе белән генә яши. Алар гармун сатып ала алмаслар иде. Хәзер дәртләнеп тальянда уйнарга өйрәнә.

Бу программа дәвам итсә, ике-өч елдан нәтиҗәсен бирәчәк. Тальянчылар дуэтлары һәм триолары барлыкка киләчәк. Әлеге инструментларны республика конкурсларының төп призы итәргә дә була», – ди Сарман районы Җәлил балалар музыка мәктәбе укытучысы Рәмзия Йөзлебаева.

## «ӨЛКӘННӘРЕБЕЗ ДӘРТЛӘНЕП ӨЙРӘНӘ... »

«Эшләгән эшебезне күрделәр – безнең мәдәният йортына да быел тальян бирелде. Авыл клубларына музыка кораллары бик

«Татар-информ» архивыннан

Салават Камалетдинов фоторәсеме



кирәк. Тагын да булсын иде әле гармуннар, курайлар. Быел мәдәният йортыбыз 100 мең сумлык Республика грантын отты.

Авылыбызда ансамбльгә йөрерлек әби-бабайларыбыз да бар. Фольклор ансамбленә йөргән Фәйрүзә апа бервакыт тальянда уйныйсы килү хыялын әйтте. Аның теләген әләктереп алып, авыл мәдәният йортында «Әүлия моңнары» тальянчылар ансамбле оештырдык. Чөнки тальянда уйнау хыялы булган өлкәннәребез тагын да бар булып чыкты. Аларны Җәлил сәнгать мәктәбеннән Рәмзия Йөзлебаева килеп укыта. Ул – тальянны популярлаштыру хыялы белән янган укытучы. Иренми, килә, әби-бабайларыбыз бик дәртләнеп өйрәнә. Ансамблебез, ветераннарның «Балкыш» фестивалендә катнашып, республика турына үтте», – ди Сарман районы Иске Минзәләбаш авылы мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе Эльвира Мөхәммәтҗанова.

## ТАЛЬЯН ТАВЫШЫ – ТАТАР МИЛЛӘТЕ ТАВЫШЫ

Сәнгать фәннәре кандидаты, фольклорчы галим Геннадий Макаров фикеренчә: «Тальян тавышы – татар милләте тавышы. Тальян Европадан Россиягә 1812 елгы сугыштан соң керә башлаган. Парижга барып җиткән меңәрләгән солдат трофейлар белән кайткан: Россия дә гитарада, физгармониядә уйный башлаган. Шулай итеп, Европа яңалыгы Россия мәдәниятенең бер өлешенә әверелгән. Татарлар алдынгы милләт буларак, тальянканы тиз үзләштереп алган һәм үзләренә җайлаштырган.

Татарлар гармунны борынгы заманнарда «әргән» дип атаганнар. Традицион гармунга кадәр алар клавишлы физгармониядә уйнаганнар. Татарча итеп уйнасаң фортепиано да, синтезатор да татар инструменты була ала. Бездә ислам дине музыкага каршы булган дигән фикер яши. Бу дөрес фикер түгел. Мулла каршы булган икән, бу иске карашлар белән генә бәйле, ислам белән түгел. Татарда гармунның адаптациясе озак барган. Соңрак тальянда уйнау – татарлык эталонына әверелгән. Заманча татар мәдәнияте тальянга корылган».

## ЙӨЗЕНЧЕ ТАЛЬЯН НӘНИ БАЯНЧЫ ИБРАҺИМ ВӘЛИЕВКӘ ТАПШЫРЫЛДЫ

«Уйнагыз, гармуннар!» бәйрәме – быел да Республика көне уңаеннан уздырылган бәйрәм чараларының берсе һәм күренеклесе иде. Ул 35 нче тапкыр уздырылды.

«Уйнагыз, гармуннар!» XXXV Республика халык иҗаты бәйрәме традиция буенча Камал театры алдындагы мәйданда башланып китте. Бу бәйрәмнең традицион үз тамашачысы бар. Болар – яшьлекләрендә тальян гармун




Дмитрий Петриченко фоторәсеме

белән кичке уеннарга төшкән өлкән яшьтәге агайлар һәм ханымнар. Алар өчен әлеге бәйрәмгә килеп, милли моңнар белән илһамлану – Республика көненең ямьле бер өлеше.

Милли бәйрәмне күрергә килүче тамашачы алдында Татарстанның халык артистлары Хәмдүнә Тимергалиева, Зәйнәб Фәрхетдинова, Рөстәм Закиров, Гүзәл Уразова, Татарстанның атказанган артисты Ришат Төхвәтуллин һәм башкалар чыгыш ясады. Гармун бәйрәме булган җирдән, әлбәттә, Татарстанның Дәүләт җыр һәм бию ансамбле дә читтә кала алмый.

Бәйрәмнең концерт өлеше флешмоб буларак дәвам итте: Татарстанның 43 районыннан килгән 100дән артык гармунчылардан торган төркем Казан кирмәненә таба юл тотты.

«Без быел векторны бераз алыштырдык. Ул Казан Кремленнән Иске татар бистәсе ягына түгел, киресенчә – Камал театры яныннан башлыйбыз, анда концерт. Аннары гармуннар белән Казан Кремленә барып, «Уйнагыз, гармуннар!» фестивале эстафетаны TAT CULT FEST яңа татар мәдәнияте фестиваленә тапшыра. Моның асылы – мәдәни традицияләрнең буыннан-буынга күчүен һәм өлкән буынның мәдәни кыйммәтләрне яшь буынга тапшыруы», – дип аңлатты Татарстан Республикасының Мәдәният министры Ирада Әюпова бәйрәм турында.

Бәйрәм 1 нче Май мәйданында дәвам итте. Биредә баянчыларга республиканың фольклор җыр һәм бию ансамбльләре дә кушылды. Бәйрәмнең кадерле кунаклары – Бөтендөнья Татар конгрессы оештырган «Милләт җыены» делегатлары иде.

Җыелган кунакларны һәм гармунчыларны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шура рәисе Васил Шәйхразиев сәламләп, бәйрәм белән котлады. Татарстан Республикасы Президенты ярдәме белән яшь гармунчыларга бүләк итеп бирелә торган 100 гармунның символик 100 нче данәсен дә яшь талантка ул тапшырды.

Йөзенче тальянга нәни баянчы Ибраһим Вәлиев ия булды. Өч яшеннән сәхнәгә баян күтәреп чыккан нәни Ибраһимны тамашачы яхшы хәтерли. Ул танылган баянчы Ренат Вәлиевнең улы.

**Рузилә МӨХӘММӘТОВА**

# Тал бөресе

*(Татар халык җыры)*

*Тал бөресе, тал бөресе,*
*Тал бөресе талларда;*
*Сандугачым, әйтеп сайра,*
*Сөйгән ярым кайларда?*

*Сандугачым, очасыңмы,*
*Кипте инде күлләрең;*
*Синең янга барып кайта*
*Һәр көнне күңелләрем.*

*Моңлы кичтә тальян гармун*
*Кемнәр уйнатыр инде.*
*Син булмагач күңелемне,*
*Кемнәр юатыр инде.*

*Агыйделләр дулкынлана,*
*Дулкынлана, комлана;*
*Басып сайрар талы сынса*
*Сандугач та моңлана.*

*Гармуныңны тартып уйна*
*Үрләргә менгәндә дә.*
*Онытасым юк үлгәндә дә –*
*Гүрләргә кергәндә дә.*



Дмитрий Петриченко фоторәсеме



«Татар-информ» архивыннан

Салават Камалетдинов фоторәсеме

# Ак КАЛФАК

*Калфаккайларыңның, ай, түбәсен,
Түп-түгәрәк итеп лә кем куйган?
Кашларың ла кыйгач, йөзең сылу,
Исемнәрең матур, кем куйган?*

**Җырларда җырланган «ак калфак» – милли киемнең татар мәдәнияте символикасына әверелгән матур бер өлеше. Сүзтезмәдәге «ак» сүзе баш киеме тегелгән тукыманың ачык (ак) төсен генә күрсәтеп калмаган, чигештәге көмеш ука җепләрнең якты җемелдәвен дә аңлаткан. Калфак образы төсмерләре аша халкыбыз кыз баланың гүзәллеген һәм күркәмлеген җырга салган: «Безнең дә сөйгәннәр шулар була: хәтфә калфак башында», «Калфагым бөдрәсе ак ука», «Ак калфакта алты чук, алтысы да алтын чук», «Калфаккайларыңның, ай, түбәсен, түп-түгәрәк итеп лә кем куйган?».**









**Алтын җепләр белән чигелгән бәрхет калфаклар.
19 йөзнең икенче яртысы. Казан татарлары. Н.И. Воробьев һәм П.М. Дульскийның 1923 һәм 1925 еллардагы тупланмалары**

Әлеге образларны Татарстан Республикасы Милли музее тупланмалары үрнәгендә барлый алабыз.

Хатын-кыз баш киеме ике төргә – яшь туташлар һәм кияүдә булган ханымнарныкына бүленә. Ханымнарныкы күп төрле булып, аларга чәч җыя торган эчке баш киеме һәм өске япмалар, бәйләвечләр дә өстәлгән. Кешелеккә дигәне – кунакка бара, бәйрәмгә чыга һәм төрле йолалар вакытында киелә торганы – кул эше осталары тарафыннан затлы бизәлә. XIX гасырда татар хатын-кызлары өчен баш киемнәрен күпләп җитештерү эше җайга салына.

Калфакның берничә варианты булган, алар ясалган тукымасы һәм бизәкләү ысуллары белән аерылып торган. XX гасыр башына кадәр татар хатыны киеп йөргән баш киеме нигезендә гади колпак ята. Ул бәйләм энәләре белән оек кебек итеп түгәрәкләп бәйләнгән дә, урталай бөкләнгән. Аның бер яртысы икенчесе эченә урнаштырылган, очына чук тагылган. Бәйләнгән калфакның озынлыгы 70 сантиметрга кадәр җиткән. Аны маңгайга төшереп кигәннәр, ә конуссыман очы артка яткан яки кырын салынган. Калфакның төп бизәге «ука-чачак» дип аталган маңгай бәйләвече булган.

*Аршын гына аршын ак ука*
*Калфак кырыйларын каюга…*

XIX гасырның беренче яртысында традицион калфакның төрле фасон һәм бизәк вариантлары булган. Мәсәлән, калфак төсле аркылы сызыклы трикотаж тукымадан ясалган. Мондый төр калфак Г.Ф.-Х. Паулиның «Россия халыклары» альбомындагы (Санкт-Петербург, 1862) литографиясе аша тарихка кереп калган. Рәсемдә – хәлле татар гаиләсендә үскән яшь кыз, башында чигешле калфак, калфакның маңгаена төшеп торган алтын төсле чугында энҗеләр дә шәйләнә. Шәһәр кызлары калфагын көмеш җепләр белән бизәлгән ука-чачак әйләндереп алган. Калфакның маңгай өлеше генә түгел, аскы өлеше дә алтын һәм көмеш җепле чуклар белән бизәлгән, энҗе һәм сәйләннәр тезелгән, хәрәкәтләнгәндә җилфердәп, чәч толымнарындагы чулпылар,



**Энҗе калфак фрагменты. 19 йөз ахыры – 20 йөз башы. Кострома татарлары.**




**«Торговый дом Гәйн әд-дин Сабитов вә угыллары һәм компаниясе Казанда» сәүдә билгесе**

алкалар һәм яка каптыргычының зеңгелдәп торган тавышына кушылган.

XIX гасырда калфак бәрхет тасмалардан тегелгән, бизәкләре аппликациянең сирәк кулланылган үзенчәлекле ысулы – тасма кисәкләре таҗ яфраклары рәвешендә «колакландырып» бөтерелгән техника белән ясалган. Төрле төстәге вак ефәк кисәкчекләренең өчпочмаклап бөтерелүе колакны хәтерләткән – алардан күп таҗлы купшы чәчәкләр һәм бөреләр тезелгән, үзәге ялтыравыклардан, энҗеләрдән ясалган, сабагы алтын җепле һәм энҗеле булган. Зур калфакның һәр ярусына оригиналь чәчәк композициясе ясалган, бәрхет тасмалар тоташтырылган эз бөтерелгән металл җепләр чылбыры астына яшерелгән.

Татар калфагы эчке баш киеме саналган, ягъни, ул үзе генә киелмәгән, аның өстенә яулык яки шәл ябылган. Калфакның кызлар вариантында аның беренчел функциясе – чәч каплагыч булуы ачык күренә. Баш киеме кияүдәге ханымның чәчен генә түгел, муенын, җилкәләрен һәм аркасын да томаларга тиеш булган. Традицион калфак үзгәреш кичергән, XIX гасырның икенче яртысында ул бер генә төрле бәрхеттән тегелә башлаган, маңгай бәйләвече каты кырпаулы маңгайчага әверелә (юка катыргы яки кәгазь куеп сырылган тукыма). Татар киемен өйрәнүче галимә Р.Г. Мөхәммәдова күрсәткәнчә, каты маңгайчалы һәм йомшак өсле (капчык) бәрхет калфаклар XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татар хатын-кызларының кием комплектына кергән. Алтын җөйле бизәкләргә вак тәңкәләр куелуы борынгы тәңкәле бүрекләрне хәтерләтеп торган.

Казан татарларының хатын-кыз һәм ир-ат баш киемнәрен җитештерү алымнарын XIX гасыр ахырында кәсепчелекне өйрәнүче галимнәр С.А. Давыдова һәм Л.Я. Криваксина тасвирлаган, галимнәрне алтынлап чигү кәсебенең үсеше җәлеп иткән.

Бу сәнгать яшь Татарстан Республикасында да югалмаган: егерменче елларда Казан татар хатын-кызларының «Азат хатын» кооператив артеле төзелә. Биредә түбәтәйләр ясаганда борынгы чигү осталары тәҗрибәсе кулланыла. 1929 елда бу тәҗрибәне өйрәнгән Г.М. Залкинд үткән гасыр осталарыннан мирас булып калган алтынлап чигү традицияләрен һәм серләрен тасвирлап язып калдырган[1]. Бәрхетне һәм башка материалларны өлге буенча ир-ат кискән. Эш барышында иң җаваплы һәм иҗади өлеш – бизәкләр төшерү һәм кәгазь трафаретлар әзерләү – болары белән тәҗрибәле чигүчеләр шөгыльләнгән. Өлге буенча киселгән калфак кисәкләре чама белән 30x80 сантиметрлы турыпочмаклы агач кыса рәвешендәге киергегә кертелгән. Киерге чүпрәген кысага ныклап беркетеп, каты итеп тарттырып куйганнар. Әлеге киндергә чигеләсе бәрхет кисәге тегелгән, аңа бизәкнең кәгазь трафареты эләктерелгән (яки ябыштырылган). Шуннан соң иң җаваплы чигү этабы башланган – аның өчен көмеш һәм алтын канитель (фр. Cannetille – нәзек көмеш чигү җебе), XIX гасыр урталарында көмеш һәм ал-

[1] Залкинд Г.М. Кустарная промышленность Татарстана. I. История и процесс производства обуви и головных уборов. – Казань: Татиздат, 1931.

**19 йөз ахыры – 20 йөз башы калфакларын реконструкцияләү. Авторлар – А. Липина (2001), О. Марсова (1997), Р. Фәйзрахманова (1983)**











**«Колакландырып» бөтерелгән аппликацияле калфак. Автор – Л. Фәсхетдинова. 2019 ел**

тын чыбыклар кулланылган. Бизәкнең рельефлы урыннарына мамык яки тукыма кисәкләре тыгып калдырылган, аннары кул эше остасы көмеш канительне бизәкнең төрле урыннарындагы төрле озынлыктагы спиральләргә кисkән. Энәне эшнең тискәре ягыннан кертеп, канительне рәсем буенча куеп чыккан, бу җөй «чигү» дип кенә аталган. Канитель белән чиккәндә төрле алымнар кулланылган. Канительнең озын урыннары яшереп тегелгән, яфраклар һәм чәчәкләр чиккәндә аркылы кадап кызыклы рельефлы өслек ясалган. Кайбер борынгы калфакларга «марҗа акчасы» дип аталган ялтыравыклар һәм ярымай, алты таҗлы чәчәк, овал, түгәрәк һәм башка рәвештәге җемелдәвекләр кулланылган.

Татарстан Республикасы Милли музее тупланмасында сакланган көмеш белән чигелгән калфак үрнәкләре, чигү алымнарының чикләнгәнлегенә карамастан, бизәкләрнең төрлелеге, чигүченең фантазиясе белән сокландыра. Кул эше осталарының исемнәре билгеле түгел, әмма аларның эше татар баш киемнәрен данлады, алар Россия ярминкәләрендә генә түгел, Париж, Лондон, Амстердам күргәзмәләрендә дә танылды. Гайнетдин Сабитовның «Азия баш киемнәре» фирмасы продукциясе югары сыйфатлы булуы белән аерылып торган, ул Казанда сәүдә иткән, товарын Россия ярминкәләренә дә озаткан. Музейда сакланган бер калфак эчлегендә «Торговый дом Гәйн әд-дин Сабитов вә угыллары һәм компаниясе Казанда» дип гарәп шрифты белән дә, кириллицада да язылган. Кара яшел бәрхет калфак чигеше белән таң калдыра: маңгайчасындагы чигеш белән капчык өлешендәгесе аерылып тора. S формалы сабакка утыртылган тыгыз рельефлы чәчәкләр калфакка ныклык өсти. Капчык өслегендә сабак һәм аның алты таҗлы чәчәкләре, бөреләре түгәрәкләнеп килгән.

Шунысы игътибарга лаек – калфак бизәү өчен иң популяр бизәк булып чәчәкләре һәм яфраклары белән калфак өслегенә яки маңгайга таба үрелгән гөлләмә яки чәчәкле куак санала. Затлы калфакларда бу мотив катлаулы җөйләр – элмәкләр һәм «мыеклар» кушылып, төрле канительләр һәм ялтыравыклар белән ясалган композициягә әверелгән.

XX гасыр башы фоторәсемнәре мода тенденцияләренең күлмәк фасонына гына түгел, баш киемнәренә дә тәэсир иткәнлеген күрсәтә: традицион калфакның үлчәме кечерәя – ул чәч бизәге булып кадап куела торган «мөгез калфак»ка, «энҗе калфак»ка әверелә. Миниатюр калфаклар Казан татарлары арасында киң тарала. Аларны көмеш җепләр белән чигәләр. «Исхак Карташев в Казани» сәүдә фирмасы маркасы белән чыгарылган ике үрнәк Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана. Маркада фирма атамасы гына түгел, җептә көмеш булуы турында да мәгълүмат бирелгән – 94 процент. Кул эше осталары чигә торган көмеш канитель, мишура һәм алтын җепләр золотник белән үлчәнгән (якынча 4,25 г), чигүчеләргә хезмәт хакы чигүдә кулланылган канитель золотнигы үлчәменнән чыгып саналган.

Көмеш белән чигелгән Казан калфаклары Россиянең бик күп музей тупланмаларын бизи.

**Лилия САТТАРОВА,**
**сәнгать белгече, Татарстан Республикасы Милли музее генераль директорының тупланмалар буенча җаваплы урынбасары**

Фоторәсемнәр Татарстан Республикасы Милли музееннан

# Бергәләп бизибез!





Риф Якупов фоторәсеме

# Бәби мунчасы савaплы була:
## татарларның бала коендыру йоласы

***Татарда «бәби мунчасы» дип аталган бик күркәм бер йола яшәп килә. Дөрес, төрле этник һәм этнографик төркемнәрдә бәби коендыру йоласының үз үзенчәлекләре бар, без тасвирлама өчен нигез итеп, Татарстанда яшәүче татарларның йолаларын алдык.***

Бәби коендыру борын-борыннан санитария-гигиена процедурасы гына түгел, керләнүдән саклау чарасы да, теләк теләп уңай сыйфатлар иңдерү дә, баланы җәмгыятьтә яшәргә әзерләү дә. Болар барысы да балага тереклек нигезе һәм яшәү чыганагы булган су аша кертелгән.

Элек татарлар бәби коендырырга кендек әбисен чакырганнар. Ә ул инде бәби коендыруның бөтен нечкәлекләрен белгән, бу эшкә бик җаваплы караган. Коендырганда учлары белән сыйпап сабыйның башын «йомрылаган», гәүдәсе буйлап кулларын йөртеп буен «үстергән», кул-аяк бармакларын ышкыган, колакларын, күзләрен, борынын, авызын юган.

Яңа туган баланы мунчада коендыруга әле дә зур игътибар бирелә. Кагыйдә буларак, хәзер бәбине әни кеше үзе яисә аның әбисе юындыра. Бала коендырганда: «Бисмилляхир рахманир рахим. Башлары очлы булмасын, түгәрәк булсын, буыннары нык булсын, борыны суласын, күзләре күрсен, колаклары ишетсен, авызы сөйләсен!» – дигән сүзләр кабатлана (Яшел Үзән районының Бишнә авылыннан А.Г. Галиуллинадан (1942 елгы) язып алынды). Бу теләкләр баланың җитлегүен билгели. Баланың кашларын йөзек белән «сызып» кую – аларның куе булып үсүен теләү (Кама Тамагы районының Ишим авылыннан А.Р. Хәйретдиновадан (1971 елгы) язып алынды).

Татарлар бәби мунчасына, ягъни, яңа туган сабыйны коендыру өчен ягылган мунчага аеруча зур игътибар бирәләр. Йоланың үз ритуалы булып, ул барлык нечкәлекләренә кадәр төгәл үтәлә. Әйтик, бәби мунчасы бала тудыру йортыннан ана белән бала кайткан көнне (элегрәк – бала өйдә тудырылганда – бала туган көнне) ягыла. Элек бәби мунчасы церемониясе өч, җиде, кайбер якларда кырык көнгә кадәр дәвам иткән. Аның беренче көннәре аеруча әһәмиятле булып, символлар белән тулып торган.

Бу көннәрдә ягылган мунча бәби өчен генә түгел, йолага катнашучыларның һәрберсе өчен чистарыну һәм яңарыш йоласына әверелгән. Борынгы заманнарда бәби мунчасында бала коендырудан тыш, бала тапкан хатынга да игътибар ителгән – аның эчен, билен сылаганнар. Моны кендек әбисе, яисә, тәҗрибәсе булган башка берәр хатын-кыз башкарган. Бу – бала тудырган хатынны тиз арада аякка бастыру өчен кирәк булган. Яшь ананың бала күтәргәндә һәм тулгак тотканда төшергә мөмкин булган аналыгын күтәртү өчен шулай тырышканнар. Чөнки аналыгы («умай», «бала урыны», «бала бүкәне») төшкән хатынның алга таба балага узмау куркынычы бар дип саналган. «Бала бүкәнен җайлаштырып, утыртып куярга кирәк дип, шушылай иттереп сылыйдыры инде» (Биектау районы Ювас авылыннан М.К. Гәрәевадан (1931 елгы) язып алынды); «Кендек әбисе бала тапкан хатынның бөтен җирен сылый, себерке белән парлый. Умай утырсын диер иде» (Мамадыш районы Кумырык авылыннан А.Н. Мансуровадан (1937 елгы) язып алынды). Гадәттә тәнне сабын белән ышкыганнар, әмма балчык белән ышку турында да мәгълүматлар бар. «Әбиләр мунчага килеп эчләрне сылыйдырие балчыкка» (Биектау районы Битаман авылыннан Р.Х. Гарифуллинадан (1935 елгы) язып алынды).

> ***Бала коендырганда бик күп матур теләкләр әйтелә. Аларның бер өлеше сәламәтлек, озын гомер, бәхет теләсә, икенче өлеше – тәүфикъ, олысы-кечесенә ихтирамлы булуны теләгән. Мәсәлән, «Суы сарыксын, үзе калыксын! Чыршыдай озын, нараттай кызыл, имәндәй таза, каендай зифа булсын!»***

Татарларның бала коендыруга бик җаваплы каравын билгеләп үтәргә кирәк: бәбине бер яшенә, яшь ярымга кадәр көн саен коендыралар. Кайбер урыннарда көнгә өчәр тапкыр коендыру традициясе дә бар. Бу еш юындырылган бала тизрәк үсә дип ышанудан килә. «Малайны көнгә өч мәртәбә җуарга кушалар, тиз үсә ди-ди» (Апас районы Чирмешән авылыннан Г.Ш. Хатиповадан (1932 елгы) язып алынды). Бала коендырганда бик күп матур теләкләр әйтелә. Аларның бер өлеше сәламәтлек, озын гомер, бәхет теләсә, икенче өлеше – тәүфикъ, олысы-кечесенә ихтирамлы булуны тели. Мәсәлән, «Суы сарыксын, үзе калыксын! Чыршыдай озын, нараттай кызыл, имәндәй таза, каендай зифа булсын!» (Саба

районы Сүлә авылыннан М.Т. Зариповадан (1915 елгы) язып алынды); «Аталы-инәле булсын, тигез канатлы булсын, олыларны олы итсен, кечеләрне кече итсен, бәхетле булсын, тәүфыйкълы булсын!». Юындыру белән бергә баланы сак кына, йомшак кына итеп каен себеркесе белән дә чабалар. Баланы чапканда әйтелә торган сүзләр Яшел Үзән районы Бишнә авылында яшәүче Сөмбел Нуриевадан (1962 елгы) язып алынды: «Себеркенең яшеллеге яшьлегеңә күчсен, сафлыгы тәнеңә, йөзеңә нур өстәсен, каенның сыгылмалылыгы гәүдәңне нәфис итсен, җилдә селкенүе бәхетеңне күп итсен!».

Бәбигә дигән себерке зур булмый, баланы иркәләп кенә чапсын өчен, ул тыгыз яфраклы ботаклардан ясала.

Бәби коендырыласы суны әзерләүнең дә үз кагыйдәләре бар һәм алар халык ышануларына нигезләнгән. Әле кайчан гына суга көмеш тәңкә һәм тоз салганнар – бу баланы кара көчләрдән саклый ала дип ышанудан килә. Бала коендырасы суга тозны әле дә бик еш салалар. Кайбер якларда бала юындыра торган суның бер өлешен теләк тели-тели мунча ташына сибү гадәте дә булган (Питрәч районының Янсуар авылыннан М.Я. Степановадан (1930 елгы) язып алынды).

Шунысы игътибарга лаек: бәби коендырган беренче көннәрдә күршеләрне, туганнарны, таныш-белешне дә мунчага дәшәләр. Мондый чакыруны һәркем сөенеп кабул итә, чөнки бәби мунчасы гөнаһлардан арындыра дип санала. Бәби мунчасының могҗизаи көче турында менәниләр сөйләнә: «Бәби мунчасы саваплы була. Безнең күршедә бер әби бар иде өлкәнрәк яшьтә. «Савабы күбрәк булыр, чишмәдән ике көянтә булса да су алып миним әле бәби мунчасына, менә шушы авырткан аякларым терелер, Аллаһы боерса, сызлаган буыннарым терелер», – дип су китерде» (Мамадыш районы Тулбай авылыннан Р.П. Сөләйманова (1971 елгы) сөйләгәннәрдән); «Элек кешеләр сорап килгәннәр бәби мунчасына. «Коенып кына чыгыйм әле», – дип инде, сихәтләнеп китмәмме дип. Бәби мунчасы бик саваплы мунча санала» (Лаеш районы Ташкирмән авылыннан Ф.Ф. Билалова (1947 елгы) сөйләгәннәрдән); «Ул бәби мунчасына яшьләр керсә инде, мәхәббәтле булып күренәләр, тиңнәрен табалар. «Бәби мунчасы булдымы, керик әле, суны үзебез алып керәбез», – дип, керүчеләр була» (Лаеш районы Атабай авылыннан Җ.Х. Шаһитова (1942 елгы) сөйләгәннәрдән); «Бәби мунчасына керсәң, сөйкемле булып күренәсең диләр инде» (Кама Тамагы районы Олы Кариле авылыннан Р.И. Касыймова (1965 елгы) сөйләгәннәрдән).

Мунча кереп чыккан кешене коймаклап яки башка бер камыр ризыгы белән чәй эчәргә өйгә чакыралар, ул теләкләрен теләп, бәби күчтәнәче алып керә.

Шулай итеп, беренчедән, татарларда бәби коендыру йоласы баланың тәнен һәм рухын чистарту, яңарту йоласы булып тора дип нәтиҗә ясый алабыз. Бәби мунчасында теләнгән теләкләр аша бала үз халкының психологиясе һәм менталитеты нигезләрен, җәмгыятьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен сеңдерә. Балага аны коендыргандагы матур теләкләр аша гүзәллекне тоя белү хисе, тереклекнең иң яхшы сыйфатлары иңдерелә.

Икенчедән, бәби мунчасында юынганнан соң бала тапкан ана үз халәтенә кайта, аның тәне языла, аналыгы кабат бала күтәрергә әзерләнә.

Өченчедән, бәби мунчасы һәр юынган кеше өчен могҗизалы тереклек чыганагы булып санала. Бәби мунчасы кергән кеше аның сәламәтлекне, матурлыкны һәм сөйкемлелекне арттыра ала торган серле көченә ышана.

Ә бәби күчтәнәче бирү һәм теләкләр теләү – нәни кешене социумга кабул итү билгесе.

Бүгенге көндә бәби мунчасы йоласы Татарстан Республикасында яшәүче татарларда бала тудыру йоласы циклындагы иң билгеле эпизодларның берсе булып кала.

**Зәлия БРУСЬКО,**
**филология фәннәре кандидаты**

Чыганаклар:
1. Агапкина Т.А. «Дар» // Славянские древности: Этнолингвистический словарь: В 5 т. Т. 2: Д (Давать) – К (Крошки) / Под общ. ред. Н.И. Толстого. – Москва: Международные отношения, 1999. – 697 с.
2. Баязитова Ф.С. Халык традицияләре лексикасы: бишек туе (йола һәм фольклор текстлары яссылыгында). – Казан: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ., 2012. – 331 б.
3. Власова М.Н. Русские суеверия: энциклопедический словарь. – СПб.: Азбука, 2000. – 672 с.
4.Татары / Отв. ред. Р.К. Уразманова, С.В. Чешко. – М.: Наука, 2001. – 583 с.

# ХАЛЫК ИҖАТЫ каян башлана яки Исәнбәт васыяте



Язучы Галимҗан Гыйльманов

**Быел татар җәмәгатьчелеге күренекле фольклорчы-галим Нәкый Исәнбәтнең 120 еллыгын билгеләп үтте. Шул уңайдан Г. Тукайның Казандагы Әдәби музеенда бик җитди сөйләшү булды, шулай ук мәктәпләрдә, урта һәм югары уку йортларында бөек шәхесебезгә багышланган чаралар узды. Иң мөһиме, Н. Исәнбәтнең юбилее әдәби һәм фәнни җәмәгатьчелекне тагын бер мәртәбә фольклор хакында, халык авыз иҗатының рухи дөньябызда тоткан урыны, үзаңыбызны, милли үзенчәлегебезне (национальная идентичность) билгеләүдәге роле хакында тирәнтен уйланырга мәҗбүр итте. «Келт» итеп, минем дә хәтергә кайчандыр Нәкый ага белән очрашуларым һәм бу очрашулар вакытында аның әйткән сүзләре килеп төште...**

...Мин ул көнне фольклорчы агай янына дустым, якташым Рамил Исламов белән барган идем. Бераз дөнья хәлләре, аннары Ш. Бабич хакында (ул бит аның турыдан-туры шәкерте) гәп куерткannan соң, Н. Исәнбәт сорап куйды: «Син нәрсә белән шөгыльләнәсең?» Диссертация язып йөргәнне белә иде агай, шуңа да бераз аптырап калдым. Ул моны шундук сизеп алды һәм кабатлап сорады: «Нинди тема белән шөгыльләнәсең?»



«Балладалар турында фәнни эш язам», – дидем. «Алайса, легендалар, риваятьләр белән таныш инде? Баллада – легендага корылган әсәр дип уйлыйм...» – диде Н. Исәнбәт, бераз уйланып торгач. «Нәкъ шулай», – дидем мин, белемемне күрсәтергә теләп. Нәкый ага тагын бераз уйланып торды. Аннары: «Баллада татарда гел булган, аның тамыры тирәндә, төрки мифларда ук», – диде. Бу минем өчен көтелмәгәнрәк сүз иде. Остазның сүзе бетмәгән икән әле: «Гомумән, бөтен халык иҗатының тамыры мифларда, риваятьләрдә, легендаларда, ышануларда... Без моңа игътибар бирмибез генә. Миф ул – ышану. Аны хорафат дип уйлап, нык ялгыштылар. Ышану начар әйбер түгел бит... Кеше ышанырга тиеш... Табигатькә, дөнья барышын билгеләгән кануннарга, кешеләргә, үзенә...»

«Фольклорны иҗат диләр, халык иҗаты диләр, ә иҗатта ышану бармы соң?» – дип сораган булдым, соравымның дөрес түгеллеген алдан ук белсәм дә. Нәкый ага миңа бик сәерсенеп карап торды, йөзен-кашын җыерып алды. Ләкин итагатьлелек белән, тыныч кына җавап бирде: «Фольклор – иҗат кына түгел. Аны мавыктыргыч әкият дип кенә уйлау бик зур ялгыш. Ул – иң элек ышану, ышанып, дөньяны танырга, аңларга омтылу...» «Сез бу турыда язгыз әле», – дидем мин. «Мин күп яздым инде. Күп эшләдем. Хәзер язу авыр, күрәсез бит, тора да алмыйм, сөялеп кенә торам... Язган чаклар булды. Мифлар хакында язып китерсәм, турап, бозып чыгаралар иде. Бер фикер калмый иде... Ләкин мин үкенмим, фольклорда җигелеп эшләдем. Гомерем буе көне-төне халык арасында, аннары өстәл артында булдым. Әйе... Эшләнмәгән бер эшем калды... Юл бирмәделәр... Мифларны чыгара алмадым... Син бит баллада өйрәнгәнсең, җый, чыгар мифларны... Син бит аларга бик якын торасың хәзер... Бөтен мирасыбызның, рухи хәзинәләребезнең, халык иҗатының тамыры мифта, ышануда...»

Ун елдан соң минем «Татар мифлары» дигән томнарым басылып чыкты. Биш том булып җыелган, бастырырга әзерләнгән кулъязма китапларның икесе генә халыкка барып иреште. Өченче томы басмаханә бүлмәләрендә югалып калды, соңгы ике томы бөтенләй дә нәшрият планнарына керә алмады. Ләкин мифларның дөньяны, табигатьне, яшәешне танып белүдә, аңлауда, гомумән, рухи дөньябызда никадәр мөһим икәнен халык беренче ике томнан да аңлап калды. Ул вакытта укучылардан килгән хатларның, өстәмә материалларның исәбе-хисабы юк иде. Шул ук вакытта Н. Исәнбәт тарихы да кабатланды: татарның фольклор фәне ике томлык «Татар мифлары»н авыр кабул итте. Дөресен генә әйткәндә, бөтенләй күрмәмешкә салышты, бу китаплардагы материаллар халык арасында телдән-телгә йөрсә дә, бер газета яисә журналдан икенчесенә тоташ-тоташ күчерелеп басылып торса да, бер генә фәнни монографиядә, энциклопедиядә дә аңа ишарә, сноска булмады.

Фольклорчылар нигә аптырап калды соң? Мифларны хорафат дип карау дәвам итәме? Бер кешенең шулкадәр тупланма җыя алуына үртәлүме? Мин хәзер якташ агаемны бик аңлыйм. Ун ел буе халык арасыннан, фонд-архивлардан, борынгы чыганаклардан җыйган олы хезмәтем бәяләнмәде. Ләкин бер хис-тойгы күңелне җылытып, үсендереп тора: аның каравы, миңа Нәкый ага ышанды; минем аның каршында – биргән сүзем, рухы алдында изге бурычым бар... Бу биш томлыкны бастырып чыгару күп чыгымнар сорый, әлбәттә, ләкин бу эштә халык үзе булышыр, дигән өмет тә бар...

* * *

Мин хәзер ныклап ышандым, хәтта инандым инде. Фольклор, халык иҗаты – иҗат кына түгел! Чынлыкта, халык авыз иҗаты – милләтне милләт итеп тота торган төп милли кодларны, символ-образларны, хикмәти фикер тәгълиматын барлап, туплап, саклап, һәр яңа буын хәтеренә сеңдереп торучы хәзинә, база ул! Мин үзем, Исламның бөтен шартларын китереп яшәгән килеш тә, Тәңре, Умай, Ер-су белән бәйле ышануларны, Шүрәлене, Су анасын, Убыр-Албастыны, Аждаһа-Юхаларны, ияләрне, «баба»ларны, ирәннәрне, шулай ук, «Йосыф китабын», «Таһир-Зөһрә» дастанын, «Идегәй», «Чура батыр» эпосларын, «Таңбатыр», «Дутан батыр», «Камыр батыр», «Турай батыр» әкиятләрен, халыкның борынгы җырларын белмәгән кешене чын татар дип саный алмыйм. Чын татарның теленә, сөйләменә ата-бабадан килүче хикмәтле сүзләр, мәкаль-әйтемнәр, җырлар, табышмаклар, мәзәкләр мул чәчелгән булырга тиеш. «Карурман»ны тыңлаганда елый

алса, Алдар, Шомбай әкиятләрен тыңлаганда рәхәтләнеп елмая-көлә алса, кеше белән сөйләшкәндә хикмәтле сүз, мәкаль-әйтем кыстырып җибәрә алса гына чын татар була аладыр адәм баласы... Милли йолалар белән җан җылытып, күңел рухландырып яшәгән, үскән, үзе дә бала тәрбияләгән кеше генә, минемчә, чын милләт әһеле дип саналырга хаклыдыр. Татарлар турында гәп куерта-куерта, егерме-утыз бит язып та, бер татар символы яки образы, сурәте, әйтеме, хикмәте, атамасы кулланмаган язучыны татар язучысы дип санамыйм мин. Димәк, ул әдипнең милли программасы бозылган, рухы имгәнгән, мең еллык рухи һәм әхлакый кодлары онытылган... Минемчә, борынгы миф-ышанулардан, халык йолаларыннан, рухи һәм әхлакый тәгълиматлардан, шуларны җыеп, барлап, һәрдаим искә төшереп торучы халык авыз иҗатыннан читләшкән кеше өчен яшәешнең тарихи һәм мәдәни әһәмияте бетә; андый кеше бик тиз күңел моңын да, телен дә, әхлакый кодексын да, хәтта динен-иманын да югалта башлый...

* * *

Ә бит кешелек барышы ике яссылыкта язылып (сөйләнеп) барыла, – аның легендар тарихы бар, рәсми тарихы бар. Бүген без күбрәк рәсми тарих белән эш итәбез, дөресрәге, без аны үзебезгә ничек кирәк, ничек җайлы һәм ничек файдалы, шулай язабыз, шулай кулланабыз да. Чыганакларның да үзебезгә яраклысын гына сайлап алабыз... Һәр тарихи формация саен үзгәреп, «дөресләнеп» торган тарихка кайчагында ышаныч та бетеп куя... Ә инде бездән соң килгән буыннар ул тарихны тагын ничек шәрехләр – бу хакта уйларга да куркыныч!

Һәм легендар тарих бар. Бөекләребезнең шундый сүзе калган: «Зур легендасы булган халык кына – бөек халык». Бабаларыбыз фикеренчә, ыру-кабиләләр, милләтләр, халыклар кан коюлы сугышларда ничә тапкыр җиңүләренә һәм нинди халыкларны буйсындыруына, хәтта күпме җир-су яулап алуларына карап кына да түгел, ә бөек рухи тәгълиматларына, дөньяны күзаллауларына, үлемсез дастаннарына, легендар җыруларына, тылсымлы әкиятләренә, хикмәтле сүз-мәкальләренә, тамырлары белән магик ышануларның иң борынгы катламнарына барып тоташкан табышмакларына карап бәяләгәннәр. Чынлыкта, без кыргызларны – «Манас», үзбәкләрне – «Алпамыш», башкортларны – «Кузы Көрпәч белән Бәян-Сылу», «Урал батыр», Себер татарларын – «Мешәк Алып», казахларны «Каимбатыр», «Йир Төшлек» дастаннары буенча өйрәнәбез... Ә төркиләрнең уртак дастаннары, легендар тарихлары күпме?! Шул ук «Йир төшлек», «Җик Мәргән», «Түләк» («Түләк белән Сусылу»), «Кузы Күрпәч», «Ак күбек», «Идегәй», «Буз егет» һәм башка эпослардан, «Кисекбаш», «Сәйфелмөлек», «Шәхсәнәм һәм Гариб», «Ләйлә белән Мәҗнүн» кебек китаби дастаннардан, иманым камил, төркиләрнең уртак тарихын менә дигән итеп күзалларга һәм өйрәнергә мөмкин. Борынгы мифологик һәм фольклор системаларын бөтен килеш саклап калган чуваш халкына (ике йөз тура (тәңре) тәгълиматы), якутларга, Алтай төркиләренә сокланмый мөмкин түгел! Шуңа да аларның тамырлары нык, аларда милли рух көчле, минемчә.

Соңгы вакытларда авыл, бистә, шәһәр тарихларын, легенда-риваятьләрен барлау, туплау, өйрәнү көчәйде. Милләттәшләребез, кардәш төрки туганнарыбыз арасында үзләренең асылларын, башлангычларын ачыклауга омтылыш күзәтелә башлады, нәсел һәм авыл шәҗәрәләрен өйрәнү ихтыяҗы артты. Димәк, халык арасында милли үзаң үсте, шушы милләттән булуы өчен горурлык хисләре өскә калыкты, аның киләчәктәге яшәеш, алгарыш максатын билгеләде.

* * *

...Бу минутларда минем колакта моңлы мөнәҗәт аһәңе яңгырап тора. 90 яшьлек Әнкәй үзе чыгарган яңа мөнәҗәтен көйли... Кулымда – каләм, шушы мәкаләне язып утырам... Өстәл читендә – кайчандыр Нәкый Исәнбәт төзеп бастырган, калынлыгы бер карыш кына булган «Мәкальләр» китабы. Бу китап хакында кайчандыр күрше карты – Сабиров Шакир агай, Ш. Бабичның шәриктәш дусты – ерак 70 нче елларда ук: «Бу – татарның Корьәне» дигән иде...

Мин туган нигеземдә – Әсән авылында.

**Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ,**
**әдәбият белгече, язучы**

# ТАТАР ЭПОСЫ нинди ул?

**Эпосны халыкка җиткерүче кешеләрне төрле халык төрле исем белән атап йөрткән. Борынгы греклар аларны «аэд»лар дип атаган, борынгы һинд эпосын әйтүчеләр «сут» яки «кушелав»лар дип йөртелгән, Көнбатыш Африкада бу төр шөгыль ияләре «гриот»лар, Көнбатыш Европада «шпильман»нар дип аталган, рус халкы үзләренең «сказитель»ләре белән горурланган, украиннарның «кобзарь»лары булган. Монгол телле бурятларда мондый осталарны «улигершин» яисә «гесершин», ә алтайдагы төрки булмаган кайбер халыкларда «хайджи» дип атау кабул ителгән. Эпос-дастан таратучыларның төрки халыкларда да исемнәре төрле: олонхосут, шагыйрь, җомакчы, ашуг, бахшы, сәсән яки кобайырчы, акын, манасчы, кыйссахан, кайчы һәм башкалар.**

Эпосны халыкка җиткерүче башкаручы-импровизатор иҗаты – язмага кадәрге культураның бер чагылышы. Эпосны телдән әйтү күчмә тормыш шартларында озаграк яшәгән, мөселман культурасын соңрак үзләштергән яисә ислам тәэсирен бөтенләй кичермәгән халыкларда стабиль сакланган. Халык шигыренә нигезләп, зур-зур вакыйгалар турында тоташтан сөйләп бирү фольклорда дастан (эпос) жанры булып ныгыган.

Кыргызларның бүгенге көнгәчә телдән башкарыла килгән «тере» эпос үрнәге «Манас»ын алыйк. Әлеге әсәрнең Җәнәк исемле батырга багышланган өзегеннән бер мисал:

*Баздышам тентушка соога ыргыткан,*
*Беежинге барса жол салган,*
*Баздышам беш жуз киши косшу алган.*
*Байбише калды сарайда,*
*Балдарын асар далайда.*
*Жоомокто сиздей кимде бар.*
*Саната Манас болбосо,*
*Сайганы сиздей кимде бар[1].*

Күргәнебезчә, биредә чичән, сөйләм уңайлылыгы, хәтердә калдыру җайлылыгы, шигъри яңгырашның камиллегенә таянып, бер авазга башланган юлларны тезә-тезә дә, башка авазга күчә. Архаик чорлардан ук фольклорда киң кулланылган нәкъ шундый ук мисалларны алтай, саха, нугай, казакъ, үзбәк, азәрбәйҗан, кыргыз, төрекмән, кырым татарлары, себер татарлары, хакас, шор һәм башка төркиләр, шулай ук бурят, монгол һәм башка төрки булмаган халыклар иҗатыннан да күпләп китерергә мөмкин булыр иде. Шушындый традицион ысуллар аша эпоста халык идеологиясе, фикере җиткерелгән.

Чын җомакчы-импровизаторлар, әнә шулай, халык шигыренә таянып, бер сөйләгәнен кабат кабатламыйча, айлар буе бер үк эпопеяны башкарулары белән дан тотканнар. Көньяк Себер һәм көньяк халыкларының күпчелегендә эпоска мөнәсәбәттә мондый традиция әле бүгенге көндә дә югалмаган.

Югарыда китерелгән мисал очрагында халыкта дастан жанрының нәкъ менә шушындый формада, ягъни силлабикага, аллитерациягә, такмаза шәкеленә, сарынга – халык шигыренең һәм прозасының төрле ысулларына, гомумиләштереп әйткәндә, традицион халык стиленә таянган архаик жанры һәр халыкта бар, яисә булган һәм тиешле дәрәҗәдә сакланган дип тә әйтеп булмый. Шуңа күрә кыргызлар үзләренең «Манас»ы, каракалпак, казакълар, нугайлар сөйләмә «Баян-Сылу», «Кузы Көрпеш», «Идегәй», «Шора батыр» версияләре, шулар ук һәм үзбәкләр «Алпамыш», «Ләйлә белән Мәҗнүн», якутлар күпләгән олонхолары белән һәм шушы «тере» эпосны төрле вариантта халыкка һәм фольклорчы галимнәргә тапшыра килгән халык вәкиле – чичән-импровизаторлары белән хаклы рәвештә горурланалар.

[1] Ауэзов М. Собрание сочинений. В пяти томах. Т. 5. Литературно-критические и публицистические статьи 1936-1961 годов. Перевод с казакъского. – М.: «Художественная литература», 1975. – С. 393-394.

Игътибар итсәк, татарларның иң оештыручы үзәге саналган Идел буенда эпосның мондый төре, ягъни көннәр-төннәр буе думбра чиртеп әйтелә торган беренчел формасы тулы килеш сакланмаган. Биредә импровизаторлык таланты белән аерылып торган кешеләр булган һәм, шиксез, алар әле дә бар, андый кешеләрне чичәннәр дип атаганнар.

Татар чичәне туй-мәҗлесләрдә көтелгән кунак булган, төрле вәзгыятьтә оста сөйләве белән җәлеп иткән. Кагыйдә буларак, ул – үзе яшәгән төбәкнең грамотасыз мөхтәрәм кешесе, фольклор музыка коралларында да уйный белгән. Н. Исәнбәт «чичән» сүзенең халыкта сүз остасы мәгънәсендә йөрүен әйтә, казакъларны, башкортларны мисалга китереп, «соңгыларда токтарсыз рәвештә җыр чыгарып әйтә алучы берничә халык шагыйренә сәсән исеме» бирелүен искә ала һәм бу очракта «чичән» сүзенең «матур сөйли белүче генә түгел, илһами рәвештә, кәгазьгә язмастан, токтарлыксыз шигырь әйтүче-импровизатор» мәгънәсен дә үз эченә алуын күрсәтә[2].

Әмма татар чичәне без алдарак карап үткән эпос әйтүче импровизатор образына бик үк тәңгәл түгел. Татар халкы тарихи хәтерендә чичән образлары бар барын. Алар нигездә гомумтөрки саналалар: Җирән чичән, Сыпра (Субра) җырау, Җамукай чичән яисә Идел-Урал төбәге шагыйрь-импровизаторлары саналган Әсән Кайгы (XV гасыр), Казтуган җырау (XV гасыр), Дусмәмбәт җырау (XV гасыр ахыры – XVI гасыр башы), Чалгиз (Шалкиз) җырау (XV гасыр ахыры – XVI гасыр уртасы) һәм башкалар. Соңгы чорда Урта Идел татарларының талантлы чичәннәреннән Сабирҗан акын (Әтнә районы Мәңгәр авылыннан), Байчыгави (Лаеш ягыннан), Кәшшафетдин Шаһимәрдән Минзәләви (Минзәлә өязе Сөлек авылыннан), Хөсәен Нугай һәм башкалар – чичәнлекләре белән шулай ук билгеле шәхесләр. Әмма боларның репертуарында дастаннар түгел, күбрәк халык җырлары, афоризмнар, тылсымлы һәм батырлар турындагы әкиятләр, хикмәтле сүзләр өстенлек алган була. Атап әйткәндә, чичәнлек Идел буе татарларында иң беренче чиратта эпос жанрында түгел, үзгә функциядә ачылган.

[2] Татар халык мәкальләре / Җыючысы һәм төзүчесе Н. Исәнбәт. 3 томда. Т. 1. – Казан: Татар китап нәшр., 1959. – Б. 67.



Идел буе татарларында тел остасы-чичәннәрнең дастан жанрыннан ерагаю сәбәпләренә килсәк, бу иң беренче чиратта биредә дастани эпосның язма-китаби юнәлештә үсеш алган булуына бәйле. Фольклор тамырлы классик әдәбиятның борынгы һәм урта гасыр үрнәкләре халык иҗатына хас рәвешкә китереп эшкәртелгәннәр, язып таратылганнар, нәтиҗәдә язма формалы эпик мирас булып әверелгәннәр. Әйтик, мәгълүм сюжетлы «Таһир белән Зөһрә», «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Йосыф китабы», «Сәйфелмөлек» кебек дастаннар Идел буе татарларында әллә ничә вариантта билгеле. Халык вариантларыннан тыш боларның индивидуаль авторның оригиналь әсәре булып танылган версияләре дә мәгълүм. Гомер бакый дәүләт тотып яшәгән татарның дәүләтчелек идеясен XV гасырдан бүгенге көннәргә китереп җиткергән «Идегәй» дастаны мисалында да китабилык ачык чагыла. Заманында Алтын Урда составына кергән башка күп кенә халыкларда таралып та, иң камил дәрәҗәдәге язма-китаби формалы «Идегәй» версиясенең татарда гына сакланган булуы игътибарга лаек.

Идел буе татарларында дастани эпосның язма әдәбиятка гына түгел, гомумән язмачылыкка, язма культурага бәйлелеге, хәтта буйсынган булуы төрле факторлар аркасында гаять киң җәелеп, тора-бара халык дастаннары таралыш-яшәешендә масса характерын алган. Казан татарлары дастани мирасының иң зур күпчелеген китаби дастаннар тәшкил итә. Башка төрки халыклардагы версияләре импровизаторларның авыз-тел иҗаты буларак таралган дастаннар да Идел буе татарларында китаби булып формалашканнар. Мәсәлән, алда телгә алынган атаклы «Идегәй» дә, яисә «Чура батыр», «Түләк китабы», «Бүз егет» һәм

башкалар – барысы да татар рухи тормышына иң беренче чиратта җыручы-чичән башкаруында түгел, ә язма-китаби эпос булып кереп урнашканнар. Ә «Кыйссаи Сәкам», «Каһарман Катил», «Гыйсә улы Амәт», «Чыңгыз хан нәселе турындагы дастан» һәм башкалар – болар, гомумән, башлангычы белән үк язмада таралыш алган дастаннар.

Башка төркиләрдән аермалы буларак, Идел буе татарлары эпосында шактый иртә чорлардан ук йоладан аерылганлык күзәтелә. Кыргыз, казакъларлардагы кебек, күләмле әсәрне халык алдында билгеле бер йолага бәйле рәвештә көйләп әйтү казан татарларында берничә гасыр элек үк инде популяр булмаган. Тарихка мөрәҗәгать итсәк, Казанны яудан сакларга әзерләнгәндә, мәсәлән, татарларның чичән-башкаручыдан эпос-дастан көйләтүләре документаль дәрәҗәдә беркайда да теркәлмәгән, мондый вакыйгалар уңаеннан ул чорда биредә, әйтик, П. Рычков мәгълүматларына нигезләнеп, музыка уйнату гадәте генә гамәлдә булуын беләбез[3].

Билгеле булганча, татар халкы, бигрәк тә Урта Идел татарлары, элек-электән язма мәдәнияткә ия, китаплы халык булган. Биредә шәһәрләр һәм шәһәр культурасы гөрләгән, мәдрәсәләр эшләгән. Шуның нәтиҗәсендә Идел буе татарларында, төрки эпосның язма-китаби төре бик киң урын алган. Укый-яза белгән халык билгеле сюжетлы эпик әсәрләрнең төрледән-төрле вариантларын кәгазьгә күчереп язуны думбра чиртеп эпос әйтүдән күпкә өстен куйган. Борын-борыннан язу культурасы югары татарларда бу башкача була да алмаган!

Чичән-импровизатор функциясе дә мондый дастаннарда нәкъ менә шушы күчереп таратучы информант өлешенә тия. Китаби дастан информанты гадәттәге ашуг, бахшы, сәсән, манасчы, олонхосут белән чагыштырганда икенчел функция үти. Ул күбрәк – текстны язып таратучы иҗатчы-дастанчы. Казан татарларында бу вазыйфаны гадәттәге үтә талантлы, әмма грамотасыз, мәктәп-мәдрәсәдә укып белем алмаган халык вәкиле түгел, ә укымышлы кеше – мулла, мәдрәсә шәкерте яисә иҗат белән шөгыльләнүче башка бер шәхес үти торган булган.

Чабып барган ат тоягы тавышын, кошның очып һавага күтәрелүен, исеп үткән дала җилен, ат пошкыруын, кылыч чыңын сөйләме аша тыңлаучыга җиткерергә сәләтле башкаручы тасвиры белән чагыштырганда, язма-китаби дастан текстының икенчеллеге үзен сиздерә, әлбәттә. Тере эпик традицияләр остасының, әйтик, олонхосутның гаҗәеп хәтергә ия булуы, олонхоның сюжет үстерелешендәге катлаулы схема белән бик җиңел эш итә белүе, әсәрне башкарган вакытта сулышының эпик киңлеге, чын фольклор текстын җанландыруы белән әсир итүе бәхәссез. Язма-китаби эпоска исә динамизм, хикәяләү-бәян итү энергиясе җитенкерәми, «автор» эшкәртүе нәтиҗәсе булып, сюжетка кайвакыт эпос өчен традицион булмаган элементлар килеп керә, халык шигыренә альтернатива буларак, китап стиле һәм башкалар кулланыла. Әмма шул ук вакытта татардагы мондый төр дастан текстларына халык эпик иҗаты кануннары да барлык тулылыгы белән диярлек сыешкан, аларда эпик һәм индивидуаль иҗат башлангычлары бер-берсе белән гармониядә.

Дастанны күчереп таратучы образы үзенчә кызыклы. Күңеле белән ул – шундый ук импровизатор-сүз остасы, әмма башкаручы түгел. Ул тасвирлаган геройлар – күп вакыт җыр әйтешү осталары, ә эпизодлар фольклор мотивлары белән сугарылган була, күчерүче-иҗатчы үзе башкаручы белән сөйләүче, ягъни риваять кылучы арасында билгеле бер урынны алып тора. Бер үк сюжетлы китаби дастанның берничә вариантта таралган булуы, эчтәлек һәм форма ягыннан аларның фольклор асылын югалтмавы, эпик текст буларак камиллеге күп очракта нәкъ менә шушы күчерүче-иҗатчының иҗат мөмкинлекләренә, шулай ук аның белем һәм халык әсәрен тоя белү дәрәҗәсенә бәйле була.

Шул рәвешчә, кайбер башка халыкларда яисә үзебезнең себер татарларында сакланган, борынгырак чорга карый торган «тере» эпос белән чагыштырганда, Идел буенда эпос-дастаннар башка юнәлештә үскән, ягъни язмачылык һәм укымышлылык татар эпосын китаби иткән. Эпик традицияләрне буыннан-буынга тапшыручы роле дә биредә, әсәрне телдән башкару функциясеннән баш тартып, бөтенләй башка форманы кабул итүе белән кызыклы.

**Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,**
**филология фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты баш фәнни хезмәткәре**

[3] Рычков П.И. Опыт Казанской истории с древнейших и средних времен. – СПб., 1767. – С. 125.

75
ПОБЕДА!
1945–2020

# КЫЗЫЛ олау

**(Фольклор-хореографик композиция)**

*(«Уракчы кыз» җыры башкарыла. Ике яктан җырлап уракчылар чыга, урак уралар.)*

*Ай урагың салып иңбашыңа*
*Кояш нурларыннан нур алдың,*
*Кояш нурларыннан нур алдың да*
*Салкын чишмәләрдән су алдың.*

**1 нче кыз:** Кызлар, печәнчеләр кайта!

**Хор белән:** Печәнчеләр кайта! Печәнчеләр!



*(«Җәй айлары» җыры башкарыла. Егетләр чыга.)*

*Әрәмәдә, болынлыкта*
*Батыр егет киң сулап,*
*Чалгы тотып печән чаба,*
*Җанкай-җанашын уйлап.*

*(Алга киләләр.)*

*Эх, ямьле була җәйнең айлары,*
*Матур була болыннары, кырлары.*

*(Икенче кат кабатлаганда артка китәләр, ярымтүгәрәккә тезеләләр.)*

**1 нче егет:** Илдә уңыш мул булсын!
**Хор:** Мул булсын!

*(«Яшь егетләр, яшь кызлар» җыры башкарыла.)*

*Яшел болыннар өстендә*
*Алсу нурлар уйныйлар,*
*Җырлар җырлап эшкә бара*
*Яшь егетләр, яшь кызлар!*

*Эх, яшь кызлар,*
*Эх, яшь егетләр,*
*Матурлар, алтын кебекләр,*
*Эштә ялкын кебекләр.*

**1 нче кыз:** Иптәшләр! Районга илтәсе олаулар әзер, атлар җигүле, беренче кем звеносы кузгала?

**1 нче егет:** Беренче урынны алган Нәфисә звеносы кузгала!

**Хор:** Әйдә Нәфисәгә бер җыр!

*(«Ай-ли, Нәфисә» җыры башкарыла. Нәфисәне култыклап әйләнәләр.)*

*Ай-ли, Нәфисә,*
*Нәфисәнең маңгай чәчен*
*Тибрәндереп җил исә.*

**2 нче кыз:** Икенче булып кем звеносы кузгала?

**2 нче егет:** Икенче урынны алган Өммегөлсем звеносы барыр!

**Хор:** Әйдә әле!

*(Өммегөлсем бии.)*





*Бас, әйдә, Өммегөлсем,*
*Идәннәре бөгелсен,*
*Басуыңда зур бәхетнең*
*Чаткылары күренсен.*

**3 нче кыз:** Зәйнәп звеносы өченче урында. Өченче булып алар кузгалыр.

**4 нче кыз:** Калганнарыбыз да алардан калышмыйбыз!

*(Зәйнәп ян-якка бию хәрәкәтләре ясый, калганнар җырлап тора.)*

*Ал Зәйнәбем, гөл Зәйнәбем,*
*Рәхәт үтсен җәйләрең.*

**Нәфисә:** Иптәшләр, әйдәгез, кузгалабыз!
**Хор:** Әйдәгез!

*(Арбага ашлык капчыклары төялгән, Кызыл байрак, «Игенчегә дан!», «Сталин» колхозы икмәге» кебек сүзләр язылган транспарантлар беркетелгән. Егетләр-кызлар җырлап алга киләләр.)*

*Безнең шатлыкларга карап*
*Шатлананалар киң кырлар,*
*Киң кырларны матурлыйлар*
*Яшь егетләр, яшь кызлар.*
*Эх, яшь кызлар,*
*Эх, яшь егетләр,*
*Матурлар, алтын кебекләр,*
*Эштә ялкын кебекләр!*

**3 нче егет:** Дәүләт амбарына «Сталин» колхозы икмәген кабул ит, Ватан!

**5 нче кыз:** Илебез халкы тук булсын, эшләребез гөрләп торсын!

**Хор:** Гөрләп торсын!

*(«Эх, Зула сулары» җыры башкарыла.)*

*Самолеттан карап бардым*
*Безнең колхоз кырларын,*
*Хезмәт юлында дан алган*
*Эшчән матур кызларын.*

***Кушымта:***
*Эх, Зула сулары,*
*Матур су алулары,*
*Үзебез чәчкән кырлар буйлап*
*Күңелле барулары.*

*Җырлар җырлап, җиң сызганып*
*Эшләп йөри кырчылар,*
*Җыр белән хезмәтне бәйләп*
*Шат яши колхозчылар.*

***Кушымта.***

*Сандугачлар матур сайрый*
*Җәйге аяз таңнарда,*
*Гармун тавышы чыңлап тора*
*Язгы Сабан туенда.*

*(Җыр барганда бию хәрәкәтләре ясала. Колхозчылар җырлый-җырлый сәхнәдән кереп китә.)*

**Рәмзия ХӨСӘЕНОВА,**
**Кукмара, Зур Сәрдек авылы**

Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан

# Дәверләрдән килгән ДӘФ

*(Татар халкының иң борынгы бәрмә уен коралы дәфкә фәнни караш)*

**Дәф – Урта гасыр татар элитар сәнгатенең бер күренеше[1]. Ул Урта гасыр татар сәнгатенең язма музыкаль-шигъри әсәрләрендә классик вәзен (метр) һәм икаг (ритм) үзенчәлекләрен чагылдырып башкару өчен иң кулай бәрмә уен коралы.**



**«Ак калфак» татар фольклор ансамбле, 2006 ел**

[1] Макаров Г.М. Использование произведений старотатарского музыкально-поэтического наследия в учебном процессе. – Музыка и педагогика (Сборник статей, посвященный 125-летию КГПУ и 40-летию музыкального факультета). – Казань, 2000. – С. 119-127.

Башка кавемнәр кебек үк, татар халкының иң борынгы бәрмә уен коралын берьяклы рамлы мембранофон тәшкил итә. Аның төрле тарихи дәверләрдә үзенә хас конструкциясе, репертуары, функцияләре булган. Табигый ки, ул төрле дәверләрдә төрлечә аталган да:

1) потпәрәстлек-мәҗүсилек дәверендә, ягъни имче, күрәзә, багучы, күремчеләр кулланышында ул – «дөңгер/думбырый»;

2) классик ислами сәнгатькә бәйле татар уенчылары арасында – «дәф»;

3) яңа вакытта, ягъни җәдитчелек дәвереннән башлап, «шөлдерле барабан» дип аталган[2].

Чагыштыру өчен татар халкында киң таралган шөлдерле (кыңгыраулы) гармун атамасын[3] алыйк. Бу атама да тасвири ысул белән төзелгән.

Татар телендәге шөлдерле барабан атамасы иске татар мәдәниятенә хас түгел, чөнки «барабан» сүзе – неологизм, ул рус һәм татар телләренә XVII йөз ахры – XVIII йөз башында гына кулланышка кергән. Рус халык уен коралларын өйрәнүче галим К.А. Вертков хезмәтләре дә шуны раслый[4]. Галимнең тикшеренүләреннән күренгәнчә, барабан атамасы XVII йөз ахры – XVIII йөз башына кадәр рус телле чыганакларда табылмаган. Рус телендә бәрмә уен коралларын (мембранофоннар) – «бубен», «накры», «набат» дип атаганнар. Урта гасыр татар мәдәниятендә дә, күрше төрки халыклар мәдәниятенә караган чыганакларда да барабан атамасы бөтенләй телгә алынмый. Бу сүз яңа дәвердә генә гомумрусия мәдәнияте күренеше буларак мәйданга килеп керә.

## ҺӘР ДӘВЕРНЕҢ ҮЗ ДӘФЕ

Дәф татар музыка сәнгатендә аз өйрәнелгән уен коралы. Фактик материаллар табу кыенлыгы һәм яңа тарихи дәвернең милли сәнгатендә дәфтә башкару традицияләре югалуы, бу уен коралының онытылуына китерде.

Дәфнең татар сәнгате структурасындагы урынын барлаганда без татар мәдәниятенең даими рәвештә үзгәреш кичереп торуын исәпкә алырга тиешбез. Төрле тарихи дәверләрнең үзенә хас жанрлары, өслүбе, социаль-коммуникатив, эстетик функцияләре булган. Шулар нигезендә һәр дәвернең үз мәдәни йөзе барлыкка килгән.

Бу кагыйдә татар дәф-дөңгерләренә дә кагыла:

– имче, өшкерүче, багучы, күрәзәчеләрнең коралы булган дөңгерләр типология буенча мәдәниятнең борынгы этник катлавына карый;

– татар мәдәниятенә классик ислами сәнгать белән үтеп кергән дәф, әлбәттә, мәҗүсилектәге им-йола сәнгате дәверендәге дөңгерләрдән үзгә булып, урта гасырларга хас элитар сәнгать сыйфатларын чагылдырган;

– җәдитчелек дәверендә татар мәдәнияте европалаша башлагач, заманча оркестр, ансамбльләрдә кулланылган шөлдерле барабаннар үз функцияләре белән гадәти рус (Европа) бубеннарыннан бернәрсә белән дә аерылмаган.

## ДӘФ ТӨЗЕЛЕШЕ

Дәф сыйфатларының кыскача тасвирламасы шул – ул берьяклы мембранофон төрен тәшкил итә. Диаметры 400 мм, биеклеге 70 мм булган агач кыршаудан эшләнә. Бер ягыннан махсус эшкәртелгән бозау тиресе тарттырылып, җилем белән ябыштырыла. Кыршауның эчке ягына тимер боҗралар тагыла. Кырый ягына яисә уртага якынрак чиртү уңаена карап, дәф тавышы төрле тембр төсмерләрендә яңгырарга мөмкин.



**Дәф уен коралының схематик рәсеме. XVIII-XIX йөз башына кадәр иске татар (кадим) сәнгатендә кулланылган гомумисламият мәдәниятенең классик бәрмәле уен коралы (автор рәсеме)**

[2] Русско-татарский словарь / Под ред. Ф.А. Ганиева. – М: Русский язык, 1985. – С. 48.
[3] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. Т.3. – Казань, 1981. – Б. 540.
[4] Вертков К.А. Русские народные музыкальные инструменты. – Ленинград: Музыка, 1975. – С. 258.



Дәф уен коралы

## ДӘФНЕҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫ

Дәф Урта гасырларда инструменталь ансамбльләрдә, гаруз вәзене һәм икагына (ритмына) нигезләнгән классик язма шигърият һәм инструменталь мәкамнәр башкарганда кулланылган. Урта Идел татарлары мәдәниятендә XIX йөз уртасында дәф кулланыштан төшә. Дәфкә кушылып башкарыла торган көйләү өслүбе акрынлап сүнгәннән соң, борылмалы озын көйләргә хас музыкаль өслүб өстенлек ала башлый.

Татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә язылып алынган зикер, бәет, касыйдәләрне дәф, танбур, думбыра кебек иске классик уен коралларында башкару гамәле – татар мәдәнияте экологиясен савыктыруга, традицион сәнгатебезне саклауга һәм үстерүгә юнәлтелгән мөһим чара була алыр иде.

## ЯҢА ТАТАР МӘДӘНИЯТЕНДӘ ДӘФКӘ УРЫН БАРМЫ?

Җәдитчелек дәвере башыннан бирле татарларның мәдәни үсеше юнәлеше акрынлап шәрыкъ цивилизациясеннән гомумевропа тибына борыла. Мондый күчеш гади халыкның гадәти көнкүреш яссылыгында да, «югары» элитар (академик, профессиональ) сәнгать өлкәсендә, европалы музыкаль жанрлар өстенлек алган яссылыкта да аермачык күзәтелә. Бу күчеш татар мәдәниятендә милли музыкада яңа сыйфатлар барлыкка китерә һәм, шул ук вакытта, этник традицияләрне югалтуга, аларны унификацияләүгә китерә. Нәкъ бу чорда татар музыкасы мәдәнияте үзгәрешләр кичерә.

Татар мәдәниятенең феодаль чоры тәмамлану үзенчәлекләрен ачыклауга, татар мәдәнияте структураларында хосусый һәм гомуми үзгәрешләр сәбәпләрен тирәнрәк аңлауга бәйле тикшеренүләр, мөгаен, үз вакытын көтәдер.

Ә бит бу бик үзенчәлекле һәм кызыклы чор. Ни өчен ул вакыт татар яшьләре милли кәвеш-читекләрен, чикмән-бишмәтләрен салып штиблет, фрак, пәлтә кигәннәр, ни өчен алар «үлеп бетә язган» борынгы кыллы һәм бәрмә уен кораллардан – танбур, думбыра, дәф, гыйжык кебекләрдән баш тартып, скрипка, гармун, мандолина, пианинода уйнарга өйрәнгәннәр, концерт-театрлар оештырып, музыкаль кичәләргә йөри башлаганнар?

Җавап гади: татар мәдәнияте европалашкан һәм яңататар милли мәдәнияте барлыкка килгән. XIX йөзнең яртысына кадәр әле сакланган шәрыкъ белән бәйле «югары» элитар кадим татар сәнгатенең «җанлы» традицияләре исә, тулысынча диярлек «мәңгелеккә китеп» юкка чыга.

Әмма хәзерге вакытта, татар музыка сәнгатендә гомумевропа өслүб юнәлеше тулы гәүдәләнеш табып үсеш алды, аның барлык кануннары һәм параметрлары төзелде. Хәтта, Европа сәнгатендә кебек үк «югары» татар музыка мәдәниятендә кайбер «модернизм», «постмодернизм» кебек эзләнүләр бар, аларны юл эзләү кризисы дип тә атап булыр иде. Шуңа күрә, татар җәмәгатьчелегендә, музыкаль сәнгать өлкәсендә иҗат итүчеләр арасында да урта гасырлар чоры иске татар мәдәнияте белән бәйле «югары» элитар музыка сәнгате, классик уен кораллары белән кызыксыну көннән-көн арта бара.

**Геннадий МАКАРОВ,**
**фольклор белгече, сәнгать фәннәре кандидаты, Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе доценты**

# МУЗЫКАЛЬ фольклористика – музыка сәнгатенең НИГЕЗЕ

**Мөнәҗәтләр һәм бәетләр музыкаль фольклорыбызның төп жанрларын тәшкил итә. Милли йөзебез – ул безнең үзенчәлекле сәнгатебез, безгә генә хас булган, башка милләтләрдән аерылып торган моңыбыз, тумыштан чолгап алган традицияләребез. Аларны саклау, өйрәнү – олуг бурычыбыз.**



**Композитор Наилә Яхина**

Мөнәҗәтләр мөстәкыйль жанр дип саналса да, бу жанр Коръән китабы нигезендә үсеп чыккан. Гарәп сүзеннән тәрҗемә иткәндә, ул «Аллаһыга ялвару», «Алла белән яшерен әңгәмә», «дога», «сыктау» дигән сүз. Татарлар мөнәҗәтен дини жанр дип кенә әйтү бик дөрес булмас иде, ни өчен дигәндә, алар арасында ана белән бала мөнәсәбәтләре, бала хәсрәте, туган илдән, якын кешедән аерылу темалары да бар. Әмма барлык мөнәҗәтләрдә дә Аллаһыга мөрәҗәгать итеп, сабырлык сорала – «Сабырлык бир, Аллаһым!» – дигән сүзләр еш очрый.

Гадәттә мөнәҗәтләр тыныч, салмак әйтелә. Бәетләрдән аермалы буларак, алар кайгы-хәсрәтнең, сагышның конкрет сәбәбен сөйләми, конкрет тарихи вакыйгага бәйләми. Мөнәҗәтне үкенү, сагыну, ялвару, рәнҗү хисләре белән сугарылган жанр дип тә карарга мөмкин.

Төрле төбәктә яшәгән татарларның мөнәҗәтләре бер-берсеннән аерылып тора. Мәсәлән, Пенза өлкәсеннән кайчандыр танылган фольклор җыючы Котдус Хөснуллин язып алып кайткан «Ана зары» мөнәҗәте диатоник ладындагы алымнарда яңгырый. Аны берничә ел элек сәхнәләрдә үзем әйтеп йөргән идем. Андагы татарлар руслар белән аралашып яшәгәнгәдер, мөгаен, мөнәҗәттә бик кызыклы булып, пентатоника белән беррәттән диатоника яңгырый.

# АНА ЗАРЫ
## (Мөнәҗәт)




*Тугыз ай күтәреп йөрдем,*
*Тугач ак сөтемне бирдем,*
*Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран,*
*Баламның хәсрәтен күрдем.*

*Бишекләрдә тибрәткәндә,*
*Тала иде беләкләрем,*
*Сезләр тыныч булмасагыз,*
*Әрни иде йөрәкләрем.*

*Бала дигән асыл сачәк*
*Ананың карнында ята,*
*Баланың моңлы сагышы*
*Ананың йөзен саргайта.*

*Бала дигән асыл йыгач (агач)*
*Ананың карнында үсә,*
*Баланың моңлы хәсрәте*
*Ананың бәгърен кисә.*

*Бәгыръ балам, газиз балам,*
*Ике күземә бер кара,*
*Синең ялкынында янам*
*Сабырлык бир тәгәлалла!*

Темалар төрле булса да, тулаем алганда, мөнәҗәтләр дини-фәлсәфи жанр булып санала. Мөнәҗәтләрдә төп әһәмият сүзгә бирелә, шигырь тексты төгәл, ул югары шигърият сәнгатен хасил итә. Ә көе кабатланучан җөмләдән тора һәм сүзләр белән бик бәйле булганлыктан, билгеле бер ритмик форма төзелә.

Мөнәҗәтләр гадәттә музыка коралларыннан башка әйтелә. Көй гадәттә тар диапазонда бара. Алар телдән-телгә күчеп килгәннәр, ноталары язылмаган. Мөнәҗәтләрне ир-атлар да, хатын-кызлар да әйтә. Кайбер илләрдә аны башкаручы осталар музыкага кушылып та әйтәләр, хәтта оркестр белән дә башкаралар.

Безнең җырчыларыбыз арасында да мөнәҗәт әйтүчеләр бар – танылган артистлар Зәһрә Сәхабиева, Гөлзада Сафиуллина, Шамил Әхмәтҗанов, Мирсәет Сөнгатуллин һәм башкалар.

**Наилә ЯХИНА,**
**шагыйрә, композитор**

# «НОКРАТ мажаралары»

Берничә ел элек Удмуртия Республикасына комплексы фәнни экспедициягә барырга туры килде. Анда татарлар күпләп яшәгән Балезино, Юкамен, Глазов районнарында булып, шактый гына материал табып алып кайттык. Удмуртиядә археографик материал эзләп йөргәндә, кайбер авылларда безгә Пучинкә авылына барырга киңәш иттеләр. Анда, янәсе, бик күп борынгы кулъязмалар табарга мөмкин. Инде вакыт кичкә таба якынлашса да, без башка экспедиция әгъзаларыннан аерылып, шул Пучинкәгә киттек. Авылга килеп керүгә мәчеткә игътибар иттек һәм анда кереп чыгарга булдык. Авыл имамы Надир хәзрәт Бузанаков безне якты йөз белән каршы алып, мәчеттә саклanучы борынгы кулъязмалар һәм сирәк китаплар белән таныштырды.

Пучинкә авылында табылган материалларга килгәндә, биредә бу төбәккә кагылышлы бер кызыклы гына кулъязма китап табылды. Анда Нократ хакында озын бер поэтик әсәр урын алган. Ул XX гасыр башында гарәп графикасында язылган, эчтәлеге белән тормыш-көнкүреш хәлләренә бәйле. Әсәрнең исеме күрсәтелмәгән яки бөтенләй булмагандыр да, шуңа күрә шартлы рәвештә генә «Нократ мажаралары» дип куйдык. Биредә Вятка губернасы Слободской өязенең Ярослав волостендә (хәзерге Киров өлкәсенең Слободской районы) урнашкан Нократ авылы турында сүз бара.

Әлеге әсәрнең кыскача эчтәлеге болай: Глазов өязеннән бер фәкыйрь кеше Нократ авылына сәфәргә чыга. Барып җиткәч, моңа хәтле таныш булмаган бер Һади исемле муллага керергә була. Мулла өйдә булмаса да, абыстае аны бик хөрмәтләп кунак итә. Аннан соң башка муллалар да бер-бер артлы бу кешене кунакка чакыра башлыйлар. Муллалардан Һади, Салах, Таһир, Нәҗип, Әхмәдсиддыйк, Зариф, Гариф хәзрәтләрнең исемнәре телгә алына, аларга бераз характеристика бирелә. Шулай ук зур кибетләр тотучы, сәүдәгәр Бородин хакында да сөйләнелә. Нинди генә ризыклардан авыз итми фәкыйрь мөсафир, хәтта киткәндә үзенә бик күп итеп сәдакалар, бүләкләр биреп җибәрәләр. Үзенең күргәннәрен бу фәкыйрь кеше лирик герой исеменнән юмор-сатира һәм төрле сәнгать чаралары ярдәмендә тасвирлап, шигъри юлларга салган һәм менә дигән әсәр барлыкка килгән. Кызганычка каршы, автор үзенең исемен бер җирдә дә күрсәтмәгән, язып калдырмаган, шуңа күрә аның турында бер мәгълүмат та юк. Күп кенә халык авыз иҗаты әсәрләре дә, кем тарафыннан чыгарылганы онытылып, гомумхалык иҗатына әверелгән. Шул сәбәпле, бәлки, бу әсәрне дә халык иҗаты әсәре итеп карарга кирәктер.

«Нократ мажаралары» язылган кулъязма китапның үлчәме: 18х11, текстының үлчәме: 16,5х10. Күчерүченең исеме, күчерү вакыты һәм урыны күрсәтелмәгән. Кәгазе безнең илдә эшләнелгән булган, чөнки анда кысу юлы белән төшерелгән бизәкле штемпель эзе бар: «Фабрики / Платунова / № 7». Шуннан чыгып, ышанычлы рәвештә, кәгазе Вятка губернасы, Слободски өязе, Урта волостендә урнашкан Платунов фабрикасында җитештерелгән дип әйтә алабыз. Библиограф, тарихчы С.А. Клепиков фикеренчә, әлеге фабрика штемпеле 1914 елда чыккан кәгазьләргә куелган[1]. Димәк, кулыбыздагы кулъязма китап та шул дәвергә карый булып чыга. Текстлары заводта җитештерелгән шәмәхә төстәге каралар белән язылган. Кустодлары куелмаган, шулай ук пагинациясе, тышлыгы да юк. Кәгазьләр кулдан ефәк җеп белән бераз тупас рәвештә тегелеп, китап формасына китерелгән. Сакланылышы уртача дип әйтергә мөмкин, шулай да бөкләнеп ятканлыктан кайбер битләре урталай ертылган, дымлы урында ятканлыктан, төрле кечкенә саргылт кара таплар барлыкка килгән.

Укучыларга шигъри әсәрнең тулы текстын тәкъдим итәбез, аңларга уңайлы булсын өчен кайбер архаик грамматик формалар хәзерге әдәби тел нормаларына салынды, кулланылыштан төшеп калган лексик берәмлекләр астөшермәләрдә аңлатылып барылды.

[1] Клепиков С.А. Филиграни и штемпели на бумаге русского и иностранного производства XVII-XX вв. – М.: Изд-во Всесоюзной Книжной палаты, 1959. – С. 107.

Бисмилла дип чыгып киттем
Нократкa[2] барырга,
Нократка баргачтын[3],
Хәйран булып торырга.
Бисмилла дип чыгып киттем
Иртә торып таң берлән[4],
Нократтан барып кайттым
Әлхәмделилләһ[5], мал берлән.
Нократның атлары
Юлга чыккач, һич армый,
Нократны күрергә
Безнең ише кем бармый.
Нократка без бардык,
Хәйран булып без тордык,
Нократка баргачтын,
Кунак булып без йөрдек.
Машинада[6] баргачтын,
Төшеп калдым Ардаштан[7],
Бер муллада кунак булдым
Килеп кергәч бер баштан.
Машинадан төшкәчтен,
Бардым инде җәяүләп,
Нократка баргачтын,
Кердем аулак җир сайлап.
Нократның мулласының
Күңелләре шат икән,
Нократта Һади мулла
Кунак өчен ялт икән.
Бу Лүкмидә без торабыз
Кара өйдә буялып,
Һади муллага барып кердем
Йөзем кызарып, оялып.
Һади мулла өйдә юк,
Ашка киткән ашыгып,
Бибифәрбиза алып керде
Йон шәлен ябынып.
Чүпчи суның буеннан
Ата куян тотканнар,
Абыстасы юмарт икән –
Пешереп җиткерде бөккәннәр.
Бибифәрбиза кизүлидер[8]
Күгәрчен күк гөрелтәп,
Чалт-чалт итеп басып йөри,
Кала идәннәр дерелдәп.
Бибифәрбиза чәй китерә
Подносларын күтәреп,
Алдан нигъмәт китерде
Күңелләрне юатып.
Су буенда су сары,
Барып ничек тотарым[9],
Һич исемдә юк иде
Бу кадәр кунак буларым[10].
Югары өйдә чәй эчтем,
Күңелләрем йомшап,
Юмарт икән абыстайлары,
Мактасаң да, хәер шәп.
Һади мулла кайтып керде
Кояш кебек ялтырап,
Һади мулла кергән чакта
Мин торамын калтырап.
Күңел берлән кунак итте
Һади мулла тартынмый,
Унике көн кунак булдым
Нократтан артынмый[11].
Сагынганда без йөрибез
Лүкми буенда җыр җырлап,
Барган көнне дүрт мулласы
Кунак кылды бик зурлап.
Нократтагы муллаларның
Ахун мулла атасы (ягъни зур мулла).
Нократка баргачтын,
Һич килмидер кайтасы.
Бу Лүкминең фетнәсе
Бетәсе юк үлгәнче,
Җәннәткә кергәчтен,
Кемнең килсен чыгасы.
Нократка баргачтын,
Сыйлагачтын[12] куандым,
Һәр муллада кунак булып,
Бик күп көннәр юандым.
Ахун мулла безне сыйлый,
Безне сыйлау зур эштән,
Ахун мулла сәдака бирде
Егерме тиен көмештән.
Салах муллага ашка бардык
Кич атна кич[13] җыелып,
Бер өстәлгә утырдык
Утыз кеше тыелып.
Салах мулла аш китерә
Алдан төрле нигъмәт,
Һәр кешегә егермешәр тиен,
Сәдака бирде бик юмарт.
Оренбурның арасы
Казакъ чәчкән тарысы,
Нократның мулласы,
Кунак итте барысы.
Бу язуны яздым бән[14]
Йөргәнемне исәпләп,
Нократта йөргәнне
Кайчан бетерерсең хитаблап[15].
Нәҗип хәзрәт чакырып алды,
Чыгарбыз, дип болынга,
Рәхәтләнеп утырып бардым
Тимер арба турында.
Су буеннан барганда
Чыланды читек, олтаннар,

[2] Текстта Нохрат дип бирелгән.
[3] Баргачтын (диал.) – баргач.
[4] Берлән – белән.
[5] Әлхәмделилләһ – Аллага мактау булсын.
[6] Биредә сүз поезд турында бара.
[7] Ардаш станциясе.
[8] Кизүлидер (диал.) – аш-су пешерәдер.
[9] Тотарым (диал.) – тотармын.
[10] Буларым (диал.) – булуым.
[11] Артынмый (диал.) – артмый.
[12] Сыйлагачтын (диал.) – сыйлагач.
[13] Кич атна кич – кич пәнҗешәмбе.
[14] Бән – мин.
[15] Хитаблап – сөйләп.
[16] Җәмыгы – бөтен.

Чәй эчкәндә китереп бирде
Урыс бик зур чуртаннар.
Таһир мулла мөәзин берлән,
Без утырабыз сыйланып,
Су буенда абыстайлар
Йөриләрдер бизәнеп.
Хәзрәт алды чуртаннарны
Акча биреп бәйләнеп,
Чуртаннарны пешерделәр
Казан тулы май салып.
Болын буенда йөргәндә
Һәвәс килә курадай,
Су буенда без йөрибез
Казаннан килгән түрәдәй.
Су буенда абыстайлар
Йөриләрдер бизәнеп.
Хәзрәт берлән чәй эчәбез
Су буенда тезләнеп.
Су буенда кошлар сайрый,
Талдан талларга кунып,
Җәмыгы[16] көнне хозур кылдык
Ерак җирләргә барып.
Нәҗип хәзрәт тәрәккый[17],
Эчмидер ул аракы,
Алты төрле гәзит ала,
Һәрбер эше яраклы.
Шәмсекамәр абыстай
Килә суның буеннан,
Гуляньяда[18] йөргәнем
Чыгасы юк уемнан.
Нократта бакча хуб[19],
Байларында акча күп,
Гуляньяда без йөрибез
Кечкенәрәк патша күк.
Гуляньяда күрелде,
Төрле нигъмәт җыелды,
Шәмсекамәр абыстайдан
Егерме биш тиен бирелде.
Нәҗип мулла хәзрәт
Җигеп җибәрде бер кара ат,
Үз өлешне биш сум биргәч,
Миннән бетте хәсрәт.
Нәҗип мулла хәзрәт
Бал әзерли хәзерләп,
Җыен мулла ашадык
Ул балны без кадерләп.
Нәҗип мулла малы бар,
Поднос тулы балы бар,
Нәҗип мулла юмарт дип
Нократта даны бар.
Нәҗип мулла манарасын
Өрәңгедән ясата,
Манараны караганда
Таһир хәзрәт ашата.
Манарага ай салганда
Безләр[20] бардык җыелып,
Таһир мулла чакыргачтын,
Безләр кердек сыенып.
Таһир хәзрәт бар икән,
Абыстасы пар икән,
Күп мулланы сыйларга
Юмартлыгы бар икән.
Әхмәдсиддыйк чакырды
Күңеле берләнраслап,
Безгә килми калсаң инде
Җибәрермен, ди, тотып.
Әхмәдсиддыйк йортының
Түбәләре тимердән,
Әхмәдсиддыйкка без бардык
Кичкә таба эңгердән.
Әхмәдсиддыйк йортларының
Әйләнәсе яшел бакча икән,
Җәйге асыл матур көннәрдә
Чәй эчәргә яхшы икән.
Әхмәдсиддыйк корты бар,
Яшел түбәле йорты бар,
Без фәкыйрьне кунак итте,
Алты төрле балы бар.
Өе тулы сәгатьтер,
Бер арганчы санап тор,
Өе тулы җиһаздыр,
Хәйран калып карап тор.
Әхмәдсиддыйк кортларын,
Барысыны[21] күрсәтә,
Безнең ише ишәккә дә
Корт гыйлемне өйрәтә.
Әхмәдсиддыйк кортларының,
Яшникләре[22] өлгедән,
Әхмәдсиддыйк абыстае
Бүләк бирде сөлгедән.
Әхмәдсиддыйк йөрмидер
Көн дә саен байлардан,
Әхмәдсиддыйк абыстае
Бүләк бирде шәлләрдән.
Әхмәдсиддыйк китабын,
Кемнәр белсен хисабын,
Әхмәдсиддыйк муллага
Байлык бирсен күп тагын.
Әхмәдсиддыйк кортларының,
Яшникләре саплы ул,
Әхмәдсиддыйк кортларын
Җәй көн булса, саклый ул.
Әхмәдсиддыйк сәгате
Кәк-күк диеп кычкыра,
Әхмәдсиддыйк кортлары
Җәй көн бал эчтерә.

[17] Тәрәккый – прогрессив.
[18] Гуляньяе – гуляние.
[19] Хуб – яхшы.
[20] Безләр – без.
[21] Барысыны – барысын.
[22] Яшникләре – ящиклары.

Әхмәдсиддыйк кортлары
Мисле җәннәт йортлары[23],
Иртә-кич сүнмидер
Яна торган утлары.
Әхмәдсиддыйк бакчасында
Бер дә юктыр таллары,
Әхмәдсиддыйк бал ашатты,
Әле дә бетми тәмнәре.
Һади мулла бирде безгә
Чәч алырдай бритва,
Һади мулладай юмарт кеше
Бу дөньяда аз туа.
Һади мулла бирде безгә
Сиксән тиенлек түбәтәй,
Һади мулла озатты безне
Прогон хакын түләтми.
Һади мулла абыстае
Бирде зәңгәрле яулык,
Һади мулла абыстаена
Алла бирсен бик саулык.
Һади мулла абыстае
Бирде күлмәклек ситса,
Һади мулла биргән нәрсәләр
Барысы да бик истә.
Һади мулла абыстае
Бирде безгә күмәчләр,
Һади мулла, юлда эч, дип
Бирде безгә чын чәйләр.
Бу дөнья фани торыр,
Миннән кемнәр үтмиләр,
Юлда аша, дип инде
Бирде инде күкәйләр.
Һади мулла килми монда,
Ашка йөридер анда,
Һади мулла бәхете булса,
Син дә йөрерсең көн дә.
Һади мулла бирде безгә
Бүләк итеп күп китап,
Хак Тәгалә, кыямәт көн
Әҗерене кыл хисап[24].
Һади мулла бирде безгә
Юлга чыгарга акча,
Һади мулла бирде безгә
Китап йөртергә букча.
Һади мулла бирде безгә
Укымага күп китап,
Һади мулла биргән нәрсәләрне
Кемнәр бетерсен чутлап.
Безнең кияү бик уяу,
Яшь матур кызны йомдырды,
Безнең Идрис мулланы
Кызны алып тондырды.
Гариф мулла уяу кеше,
Махы бирмидер яшьләргә,
Мулла кызы Гайшәне
Үзе тырыша башларга.
Гариф мулла бик юмарт,
Яшь кыз алды – күңеле шат,
Безгә әгәр менмәсәң,
Кылыч җибәрермен, карап ят!
Гариф мулла үзе бар,
Төрле нәсыйхәт сүзе бар,
Бер җария кызы бар,
Бирәм, дигән сүзе бар.
Гариф мулла сөендерде,
Ике кичне кундырды,
Бер күлмәклек ситса биреп,
Безнең күңелне тондырды.
Язгы көндә безнең монда
Ватык була киртәләр,
Нократка баргачтын,
Бородинга кертәләр.
Бородинның кибетендә
Исле майлары тулыдыр,
Бородинда бик күп нигъмәт,
Өстәлләре тулыдыр.
Бородинның Сабиры
Ходай кылган сабырлы,
Сатуларын кыйбат бирми,
Очсыз бирә әйберне.
Бородинның кибетеннән
Бар да сату алалар,
Муллага кыз бирәләр,
Мулладан кыз алалар.
Бородинның кызлары
Йолдыздаен[25] күзләре,
Бородинның кызлары
Алпавыттай үзләре.
Бородинның бакчасы,
Бакчасында мунчасы,
Мунчасына су китерә
Җиткән өчәү духтыры[26].
Бородинның арбасының
Күннән япкан көймәсе.
Бородинның татлы икән
Майда пешкән күмәче.
Бородинның йортлары,
Яшел, кызыл сыртлары,
Бородинның, бик сөйлиләр,
Симез икән итләре.
Бородинның бакчасы,
Бакчасында кайсысы,
Су китерергә якын,
Бакчасында мунчасы.
Бородинның йортлары,
Берсе-берсе мең сумлык,

[23] Мисле җәннәт йортлары – җәннәт йортлары кебек.
[24] Әҗерене кыл хисап – әҗерен, савабын хисапла.
[25] Йолдыздаен (диал.) – йолдыздай.
[26] Духтыры – докторы.



Бородиннан бүләк булды
Безгә дигән өч сумлык.
Зариф мулла ашлыдыр,
Кече түгел, яшьлидер,
Нократка баргачтын,
Ашка чакыра башлыйдыр.
Зариф мулла чакырды
Без фәкыйрьне икедән,
Хак Тәгалә аермасын
Ахыр дәмдә ипидән.
Стойлада пар аргамак
Җикдем сыңар тәртәгә,
Олуг кешенең чакыруы
Без ишәккә мәртәбә.
Нәҗип хәзрәт чакырды
Мәҗлескә дип хат берлән,
Зариф мулланың кече углы
Яратты мине ат берлән.
Безнең Глаз өязендә
Барысы да братлар,
Салах берлән Юныслар –
Өчесе дә егетләр.
Салахетдин сатуны
Китерәдер Казаннан,
Кече энесе сатуны
Бирәдер лә арзаннан.
Безнең ише фәкыйрьне
Ашатмыйлар күп якта
Салахетдин бик юмарт,
Чакырып алды кунакка.
Нократка баргачтын,
Күрдем биек тауларын,
Салахетдиндә бар икән,
Белмәдем һич гәүһәрен.
Чыгып бардым сәфәргә,
Нократ дигән шәһәргә,
Бу Салахта кунак булдым,
Мөмкин түгел сөйләргә.
Тимер тарантас арбага
Җигеп куйганнар бармага,
Өчесе дә сәдака бирделәр,
Оят инде алмага.
Кичкә таба яндырадыр
Гелән иске лампасын,
Болар кебек юмартны
Бик күп җирдә тапмассың.
Җылы җилләр исәдер
Язгы көнне кичләрдән,
Нократка барганым
Чыгасы юк исләрдән.

**Айдар ГАЙНЕТДИНОВ,**
**филология фәннәре кандидаты**

Фоторәсем авторның архивыннан

# КАЮЛЫ КҮН дәресләре

**Халкыбызның борынгыдан килгән һөнәрләре белән кызыксынып кына калмыйча, аны үз һөнәре иткән замандашларыбыз бар. Әлбәттә, халык һөнәрчелеге белән зур бизнес ясап булмый, әмма затлы товарга ихтыяҗ була. Журнал битләре аша сезне шундый осталар – каюлы күн белән эшләүчеләр, итекчеләр, тегүчеләр, чигүчеләр, шәл бәйләүчеләр, зәркәнчеләр, керамика осталары һәм башкалар белән таныштырырбыз.**





Бүгенге кунагыбыз: Россия дизайнерлар берлеге әгъзасы, Казанның Н.И. Фешин исемендәге Сынлы сәнгать училищесы укытучысы, рәссам, каюлы күн остасы, «AyBulgari» остаханәсенә нигез салучы Айгөл САДРИЕВА.

– Безнең «AyBulgari» гаилә остаханәсе каюлы күн белән эш итә. Без халкыбызның үзенчәлекле каюлы күн сәнгатен саклап калырга һәм торгызырга, заманча эшләнмәләр дизайнында осталарның күп еллык тәҗрибәсен кулланырга омтылабыз. Остаханәнең төп идеясе – онытыла барган борынгы һөнәргә игътибарны җәлеп итү өчен аны заманча җиһазларга, аксессуарларга күчерү.












«AyBulgari» остаханәсе 2016 елда оешты. Ул вакытта мин Казанның Н.И. Фешин исемендәге Сынлы сәнгать училищесында укый, декоратив-гамәли сәнгать факультетында каюлы күн белән эш итү осталыгына өйрәнә идем. Өченче курсны тәмамлаганда мин өйдә беренче эшләнмәләремне – фермуар каптыргычы куелган акча янчыклары ясадым. Бер ханым ул янчыкларны бик ошатып, берничә данәгә заказ бирде. Бу миңа ышаныч өстәде, тагын да тырышыбрак эшли башладым. Әти-әниемә зур рәхмәт – алар ярдәме белән остаханә ачып җибәрдек. Төрле эшләнмәләр ясый башладык, әкренләп сатып алучыларыбыз артты.

Каюлы күн техникасында читек-чүәкләр, затлы букчалар гына түгел, паннолар эшләргә дә, интерьерда кулланырга да, төрле аксессуарлар җитештерергә дә мөмкин. Әмма максатыбыз сәүдә белән генә чикләнми. Безнең остаханә үз миссиясен киңрәк – мәгърифәтчелектә һәм халкыбыз һөнәрен башкаларга өйрәтүдә күрә. Максатыбыз күн мозаикасы остасы булып, кешеләргә күннән ясалган матур әйберләр тәкъдим итү генә түгел, кызыксынучыларны бу эшкә җәлеп итү дә. Әйтик, күпләр каюлы күн сәнгатен аппликация дип белә, әмма чынлыкта күн кисәкләре Казан җөе ярдәмендә бер-берсенә тоташтырып чигелә.

Борынгы техниканы саклап калу максатыннан «AyBulgari» остаханәсе мастер-класслар да уздыра. «Каюлы күн сәнгате серләре» курсында биш-алты кешелек төркем туплана. Курсларга йөрүчеләр Казан җөе белән тегәргә өйрәнә, беренче эшләнмәләрен ясый һәм аны үзе белән алып китә ала.

Рәхим итегез! Безнең дәресләр белән кулларыгыздан куанырлык булсын!

**Сөмбелә ВӘЛИӘХМӘТОВА**

Фоторәсемнәр Айгөл Садриеваның шәхси архивыннан

# СЕБЕР – дастаннар иле

**Россия тюркология мәктәбе, аерым алганда, татар фольклористика фәне В.В. Радловның «Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Джунгарской степи. Часть IV. Наречие барабинцев, Тарских, Тобольских и Тюменских татар» (Санкт-Петербург, 1872) дип аталган мәшһүр хезмәте белән башланып китә. Үзенең Германия ватандашлыгыннан баш тартып, Россия ватандашлыгын алган Вильгельм (Василий Васильевич) Радлов аны экспедицияләрдә туплаган материаллар нигезендә яза. Кызганычка каршы, В. В. Радловның бу әсәреннән соң, себер татарлары халык әдәбиятына багышланган бер генә хезмәт тә дөнья күрми.**



**Фәрит ЮСУПОВ –**
**Казан Идел буе федераль университетының атказанган профессоры, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, Халыкара Тел җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы (Төркия-Анкара), тел белеме өлкәсендәге хезмәтләре өчен Дәүләт бүләкләре иясе**

Галимнең тууына 175 ел тулган көннәрдә филология фәннәре докторы, профессор Фәрит Юсупов В.В. Радловның әлеге китабын кабаттан бастырып чыгара, Казан Идел буе университетында галимгә багышланган Халыкара фәнни конференция оештыра.

Шушы вакыйгалардан башлап, Фәрит Юсупов үзенең фәнни эшчәнлеген себер татарларының рухи мәдәниятен өйрәнүгә багышлый. Ул берничә ел эчендә себер татарларының меңәр биттән торган IV томлык антологиясен бастырып чыгара.

Аның «Себер татарлары. Рухи мәдәният җәүһәрләре. Себер татарлары фольклоры антологиясе. Дастаннар. Мөнәҗәтләр» (Казан, 2014) дип аталган I томы себер татарларының эпик әсәрләренә багышлана.

Дастан, мөнәҗәт, бәет жанрларын эпос әсәрләр дигән термин берләштерә. Ә кайбер очракларда эпос (эпик әсәр) һәм дастан терминнары бер-берсенә тәңгәл дә килә. Бик борынгы заманнарда билгеле бер кавем-халыкның язмышы хәл итела торган вакыйгалар, шул хәлиткеч вакыйгаларда үзен аямый сугышкан шәхесләр турында сөйләгән, авторы билгеле булмаган әсәрләрне «дастан» дип атыйлар. Элек бу әсәрләр шигъри формада гына булган. Тора-бара сөйләмә формада да башкарыла башлаган. Дастаннар гадәттә тантаналы вакыйгаларда башкарылган. Дастаннарның махсус башкаручылары – сөйләүчеләре булган. Аларны «чәчәннәр» дип атаганнар.

Автор себер татарлары дастаннарын түбәндәге төркемнәргә бүлеп тикшерә:

1. Мәхәббәт дастаннары һәм аларның вариантлары. Биредә башка татар төркемнәре өчен дә хас булган «Йосыф-Зөләйха», «Таһир-Зөһрә», «Сәйфелмөлек», «Бүс егет», «Кузы Көрпәч-Баян Сылу» дастаннарыннан тыш, себер татарлары өчен генә хас булган «Кәмпәр», «Шаһсәнәм вә Гариб» дастаннары да урын алган.

2. Тарихи дастаннар һәм аларның вариантлары. Аларның саны алтмышка якын. Бу бик табигый, чөнки себер татарларының мөстәкыйльлеге өчен көрәше бик борынгы гасырлардан алып, Себерне яулап алган чорга кадәр дәвам итә. Халык үзенең батырларын онытмый, аларның батырлыгын дастаннар һәм тарихи җырлар аша киләчәк буыннарга

кадәр җиткерергә тели. Халык рәхмәтен яулаган шәхесләрнең исемнәре: Бүри Хан, Атулы Батыр, Ак Буга, Би Агыш, Хуҗаш, Купланды, Тәвеш Мәргән, Хәлмәт Мәргән, Сәет, Кырамша, Туктасын Мәргән, Карьят Батыр, Сәңгәлгелек Мәргән, Тукбикә һ.б.

3. Батырлар, пәһлеваннар турындагы дастаннар. Бу әсәрләр борынгы чорларга карый. Борын-борын заманнарда илнең һәм халыкның язмышын аерым шәхесләр – батырлар, пәһлеваннар, алыплар хәл иткән. Бу батырлар барлык төрки дөньяның уртак каһарманнары булып саналган. «Йөртешлек», «Ак Күбәк», «Кара Күкел», «Алпамыш», «Межек Алып» , «Алтаин Саин Сөмә», «Йастай Мәргән», «Кадыш Мәргән» дастаннары шундый батырлар истәлегенә багышланган.

Кызганычка каршы, халык авыз иҗатының дастан жанры, башка халыклардагы кебек үк, себер татарларында да сүнеп бетеп бара.

Антологиянең II томы себер татарлары арасында иң киң таралган жанр – йомак (әкият) жанрына багышланган. Китапта 104 йомак-әкияткә урын бирелгән.

Себер татарларында әкиятләр жанры үзенең бай сюжет-репертуары һәм конфликтларның үзенчәлекле чишелеше белән аерылып тора. Алар бу җирләрнең бик борынгы хуҗалары булып саналган себер татарлары тормышының төрле якларын мавыктыргыч итеп яктырта, алар хыялланган тормышка ирешү юлларын күрсәтә.

III томда сүз себер татарлары халык иҗатында хикәят һәм риваять жанрлары турында бара. Ул татар фольклористикасында бөтенләй өйрәнелмәгән хикәят һәм риваять жанрларына багышланган. Хәзерге көндә бары тик белгечләргә генә таныш булган хикәят жанры XX гасырның башына кадәр халык авыз иҗатында гына түгел, бәлки татар матур әдәбиятында киң таралган була. Халык бу әсәрләрне бик яратып укый. Чөнки хикәятләрдә сурәтләнгән вакыйгалар, фәлсәфи эчтәлекле булулары белән бергә, көчле нәсихәт чарасы буларак та кулланылган. Бу яктан алар Ислам дине кануннарына аваздаш булган, яшь буынны гүзәл әхлаклы итеп тәрбияләүгә юнәлтелгән.

Хикәят жанры, беренче, чиратта, Ислам динле халыклар әдәбияты өчен хас. Аларның себер татарлары фольклорында куллана башлавы шулай ук Ислам диненең Көнбатыш Себердә яшәүче халыклар арасында таралуы




белән бәйле. Ислам динен таратырга килгән фарсы телле дин әһелләре дини үгет-нәсихәтләрендә хикәятләрне киң файдаланганнар. Себер чәчәннәре аларны бик тиз арада җирле шартларга җайлаштырган.

Бу томның икенче өлеше себер татарлары арасында киң таралган риваять жанрына багышланган. Себер татарларының үзләренең бәйсезлеге өчен берничә гасыр дәвамында алып барылган көрәшләрне чагылдырган вакыйгалар да, ислам укымышлыларының Себердә ислам динен таратулары турындагы риваятьләр дә фәндә беренче тапкыр гына әйләнешкә кертелә.

Себер татарларының фольклор антологиясенең IV томы музыкаль мираска багышланган. Ул нотага салынган 369 музыкаль әсәрне үз эченә ала. Аны себер татарларының көйләр иҗатына багышланган иң зур хезмәт дип санарга мөмкин. Алар түбәндәге жанрларга багышланган: дастаннар, бәетләр, йола җырлары, туй җырлары, солдат җырлары, лирик җырлар, озын җырлар, авыл көйләре, кыска җырлар, инструменталь әсәрләр.

# АК КҮБӘК

***(Дастан)***

Бер шәһәрдә Ал Бытык дигән би яшәгән, бу бидән бер угыл туган, аның атын Ак Күбәк дип атадылар, әнисенең карынында ук бала сөйләнеп яткан:

*«Мин туармын, туармын,*
*Тугач, билем буармын,*
*Төнбоеклы тирән суда*
*Тулман буем йармын.*

*Мин туармын, туармын,*
*Бу дөньяны күрермен.*
*Көмеш шәкелле җиңгәмнең*
*Авызын-борынын үбәрмен».*

Моны ишеткән кендек әбиләре качып киткәннәр. Бу бала туган. Туганнан соң, төнбоеклы тирән суга тулман буен юарга киткән. Суга төшкән. Атасының бер колы йылым тартып ята икән. Ятьмәсенә бер зур гына балык кергән булган. Яр буендагы кешеләр аны чыгара алмый яталар икән. Ак Күбәк, судан чыкканнан соң, күлмәк-ыштанын, башка киемнәрен киеп, атына менгән. Камчы сабына балыкны яңагыннан элеп, алып кайтып киткән. Әлеге балыкны өйгә китергән. Аны пешерергә кушкан, шушы балыкны бергәләп ашарга җәмәгатьне чакырырга дип, чыгып киткән.

Бара торгач, Кидән Ханны очраткан. Сәлам биргән. Тегесе сәламен алмаган. Бара торгач, Кидән Хан кабат икенче бер җирдә очраган. Ак Күбәк тагын сәлам биргән, Кидән Хан аның сәламен тагын алмаган. Аннан соң өченче җирдә очраган, Ак Күбәк тагы сәлам биргән, хан тагын алмаган. Ак Күбәк ханга өч тапкыр сәлам биргән, тегесе өч тапкыр да аның сәламен алмаган. Ак Күбәк аннан сораган:

– Атың кемдер?

– Атым Кидән хан булыр.

Ак Күбәк әйткән:

– Кидән хан дигәнче, Кутән хан дисәңче.

Кидән Хан егеттән сораган:

– Син кемсең?

– Атым Күбәк.

Хан әйткән:

– Сине нигә Ак Күбәк дип атаганнар, Сүбәк дип әйтсәләрче.

Аннан ары борылып кайтып киткән хан. Өендә Маңгыш исемле угылына әйткән:

– Ал Бытык бидән бер угыл туган, аны кече чагында ук үтер!

Аннан соң Маңгыш Ак Күбәккә килгән.

– Әйдә, алыш (дус), урманга сунарга бараек, – дигән.

Болар урманга сунарга киткәннәр. Урманда берничә көн йөргәннәр. Маңгыш моны көч белән үтерергә курыккан, берәр хәйлә табып үтермәкче булган. Маңгыш, бик ерактан уратып, сүз башлаган:

«Алыш булсаң, Ак Күбәк – ай,

Үр Колагың бир (этенең исеме), алыш – ай».

Ак Күбәк:

«Үр Колагымны бирәем – ай,

Бәһасын тапсаң, ал, алыш – ай».

Маңгыш янә әйткән:

«Алыш булсаң, Ак Күбәк – ай,

Этеңне бир миңа, алыш – ай».

Ак Күбәк:

«Этем йахшы, Маңгышым – ай,

Кыр урманга чапканда

Утыз биш төлке каптырган – ай,

Бәһасын тапсаң, ал, алыш».

Маңгыш: «Кыйбат», – дигән булып, берсен дә сатып алырга теләмәгән. Кайту юлында егетләр бер тау янында туктаганнар. Маңгыш әйткән:

– Син инде бу йакка кит, мин ул йак буйлап китәем, бу җиргә кем элек җитсә, ул соңыннан килгән кешенең башын киссен.

Ак Күбәкнең апасы бар икән. Ак Күбәк аңа әйткән:

– Бу җирдә кырык кызың белән мәҗлес җый.

Апасы килеп, кырык кыз белән мәҗлес корды. Маңгыш бу якка чыгып китте, Күбәк ул якка китте. Маңгыш килеп, Күбәк апасының мәҗлесенә юлыкты.

Маңгыш исерде, егылды. Ак Күбәк очрашырга тиеш булган җиргә җитте, Маңгышны көтеп торды. Тегесе килмәде. Ак Күбәк аны эзләп китте. Килсә, Маңгыш кызлар янында исереп йоклап ята. Ак Күбәк шунда ук Маңгышның башын чабып атмакчы булды, әмма, кылыч үтмәде. Маңгыш уянды, күзен бакты.

– Син җиткәнсең, алыш! – диде, – инде вәгъдә – вәгъдә булсын! Башымны минем кылычым белән кис! Ак Күбәк Маңгышның кылычын кулына алып күтәрүгә, алдына Хозыр Ильяс килеп чыкты:

– Кылычны күтәреп чапма! Үзеңнең башыңны кисәрсең. Кылычны җирдән сөйрәп барып кис башын!

Күбәк кылычны җирдән сөйрәп барырга булды. Шунда Маңгыш:

– Тукта! – диде. – Башымны кискәннән соң, йөрәгемне йот! Пәһлеван булырсың. Карынымны кисеп, эчәгемне алып, биленә бәйлә, аннан соң минем кылычым сиңа үтмәс булыр.

Инде Ак Күбәк, Маңгышның кылычын җирдән сөйрәп барып, башын кисеп атты. Йөрәген, йотарга дип, авызына китерде. Хозыр Ильяс әйтте:

– Йотма! Дәрьяга ташла!

Күбәк Маңгышның йөрәген дәрьяга ташлады. Дәрьяның суы казандай кайный башлады. Аш казанын тишеп, эчәгесен алды, эчәген биленә чолгамакчы булган иде, Хозыр Ильяс тагын ярдәмгә килде:

– Биленә чолгама! – диде, – агачка чолга!

Ак Күбәк, Хозыр Ильяс кушканча, эшләде. Агач, янып бетте. Күбәк өенә кайтты.

Илче Маңгышны Күбәк үтергән дип әйтергә Кидән Ханга килде. Аны ишетеп, Хан ачуына түзә алмыйча, Күбәккә китте. Кидән Ханны җиде кеше, җиде каен белән терәп, туктаттылар.

– Барма, Кидән Хан, – диделәр, – бу пәһлеван сине дә үтерер. Угылың Маңгыш синнән дә пәһлеванрак иде, аны да үтерде. Сабыр кыл, син башта гаскәр җый! Гаскәр белән барырсың, – диделәр.

Кидән Хан бармады, гаскәр туплады. Гаскәр белән Ак Күбәккә китте. Күбәк бу хәбәрне ишетеп, тау башына тимер өй салды. Кидән Ханның гаскәре шул тауның итәгендә саклап ятты. Күбәк илче чакырды. Илчедән сорады:

«Нинди-нинди пәһлеваннар бар? – ай,
Аны әйт, Чылажым – ай:
Салыр Казан – ул да бар ай,
Буйдар Алып – ул да бар ай».

Ак Күбәк үз ягында бик күп алыплар-пәһлеваннарның булганын белде. Аннан соң атына атланды, кылычын югары күтәреп, чиругә (гаскәр эченә) кереп, дошманны кырып бетерде. Аннан соң Кидән Хан белән очрашты. Күбәк сөңгесе белән ташланды, аңа җитмәде. Кидән Хан сөңгесе белән Күбәкне югарыга күтәрде. Сөңгенең сабы буйлап Күбәкнең каны акты.

Кидән хан әйтте:

– Минем угылым Маңгышның каны эчендә сиңа яхшымы иде? Бүген синең дә каның эчәр көн бар икән.

Күбәк әйтте:

– Син минем канымны эчеп торам дисеңме? Мин синең авызыңа канымны түгел, ... агызып торам.

Кидән хан сөңгесен читкә ыргытты.

Күбәк, атына атланып, кайтып китте. Кидән дә өенә юл тотты. Күбәк әйтте:

– Тагы бер атнадан гаскәрләребез белән очрашырбыз!

Сөйләп бетергесез зур орышлардан (сугышлардан) гаҗиз булган Ак Күбәк агасына кайтты.

– Агам, – диде, – инде мине җиргә күм.

Агасы аны аты белән җиргә күмде.

Күбәк әйтте:

– Бер җомга буе мине тынычлыкта калдыр! Дошман гаскәре килгәндә генә миңа килә аласың, – диде.

Өч көн булдымы, булмадымы, агасының хатыннары арасында җәнҗал чыкты. Аларны аерырга агасының көче җитмәде. Агасы Күбәкнең каберенә килде.

– Тор, Күбәк, яу килде! – дип кычкырды.

Ак Күбәк аты белән күмгән җиреннән торып басты. Як-ягына каранды: яу юк!

Агасы әйтте:

– Ике бичәм сугыштылар, мин аера алмадым. Ярдәмгә сиңа килдем.

— Инде мин чынлап та үлдем. Беркайчан да үлгән кеше кабаттан терелмәсен! Мине яңадан күм!

Егылды Ак Күбәк. Ак Күбәкне яңадан каберенә куйдылар. Бер җомгадан соң әлеге яу чынлап та килде. Агасы, Күбәкнең гүренә йөгереп килеп, чаң сукты: «Тор! Яу килде!» Күбәк, азапланып-азапланып булса да кабереннән чыгарга теләде. Чыга алмады. Агасы, Күбәкнең атына менеп, яуга китте. Ике агачны тамыры белән кубарып, сөйрәп яуның эченә ташланды. Яу да ул якка, бу якка чапты... Бу орышта бик күп алыплар-пәһлеваннар шәһит булдылар.

Кидән Хан әйтте:

– Килешәек! Синдә минем яманлыгым юк.

Аннан соң яраштылар, килештеләр, бер-берләренә яманлык ясауларын туктаттылар.

**Текстны, бераз кыскартып, әдәби телгә**
**Ф. ЮСУПОВ күчерде**

Ф.Ю. Юсупов. Сибирские татары.
Из сокровищницы духовной культуры. Дастаны.
Мунаджаты. Баиты. – Казань: Казанский
университет, 2014. – С. 143-224





# Көз кызы

Бар җиһанга колач җәеп,
Көз кызы горур атлый.
Уңыш, муллык алып килә,
Матурлыкны да саклый.

Күкрәгендә кызыл мәрҗән,
Кызыл миләш йөзләре.
Күзнең явын алып тора
Сары чуар төсләре.

Кулларында күпме байлык,
Алтын-көмеш хәзинә.
Фасылның патшабикәсе:
Көз кызы ул – Сөмбелә!

**Камилә ХАЛИКОВА,**
**Әтнә, Күшәр мәктәбенең 8 нче сыйныф укучысы**

# Сөмбелә

Чәчәкле җәйләр үтте,
«Сөмбелә» килеп җитте.

«Сөмбелә» – уңыш бәйрәме,
Яшелчә, җиләк сәйләне.

«Сөмбелә» – хезмәт бәйрәме,
Тук башаклар бәйләме!

**Алия МӨХӘРРӘМОВА,**
**Казан шәһәре, 11 нче татар гимназиясенең**
**4 нче «А» сыйныфы укучысы**



# МОҢСУ димәгез көзне...

Моңсу димәгез көзне,
Ул җәй белән янәшә,
Җиз кыңгырау көзен безне
Дуслар янына дәшә.

Ямьсез димәгез көзне –
Төсләрдән күз камаша,
Алтын икмәк, тук башаклар –
Чәчәкләргә алмашка.

Курче, Сөмбелә агачка
Алма тезгән мул итеп,
Бәрәңге басуларында
Капчык тора тезелеп.

Туган җирнең һәр фасылы
Якын миңа, чын менә,
Көзләр – кышка, кышлар – язга,
Яз кабат илтер җәйгә!

**Наилә ФАТЫЙХОВА,**
**Балтач, Салавыч күп профильле лицееның**
**3 нче сыйныф укучысы**

Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр
һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# СӨМБЕЛӘ – уңыш кызы

*(Әкият)*

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер әби белән бабай. Аларның бик чибәр акыллы кызлары-оныклары булган. Ул атлаган саен баскан эзләрендә аллы-гөлле чәчкәләр, хуш исле үләннәр, төрле куаклар үсеп чыккан. Шуңа күрә аларның яшәгән җире, күз явын алып, әллә кайдан күренеп тора икән. Әби белән бабай бу гүзәллеккә хозурланып, кызларының чибәрлегенә, аның тылсымлы көченә сокланып, тыныч кына гомер иткәннәр.

Шулай матур гына яшәп ятканда, очып баручы бөҗәкләр, күбәләкләр, бал кортлары бу гүзәллекне күреп, аптырап калганнар. «Бу нинди серле җир?» – дип, төшеп карарга уйлаганнар. Шулай итеп, алар, үләннән үләнгә, чәчәктән чәчәккә кунып йөреп, бу гүзәллектән беркая да китмәскә булганнар.

Көн артыннан көн үткән. Берзаман үләннәр кибә, чәчкәләр сула башлаган. Әби белән бабайның оныклары да аптырашта калган, чөнки баскан эзләрендә гөлләр үсми икән. Кыз бик кайгырган, өйдән дә чыгып йөрми башлаган, сары сагышка баткан. Сагыштан чәчләре дә алтын сары төскә кергән, ди. Әби белән бабай оныкларын бик кызганганнар.

Шулай бер көнне алар кызларын урамга чыгарга күндергәннәр. Кыз урамга чыгуга, тирә-юнь яктырып киткән. Аның алтынсу чәчләре җилдә таралып китүе булган, болындагы үләннәр, агач-куакларның яфраклары алтын сары төскә кергән. Кыз куллары белән әле бер куакка, әле икенче куакка кагылып алуга, аларда төрле сусыл җимешләр өлгергән. Кешеләр җимешләрне ашап караганнар да шаккатканнар: алар шундый тәмле, шундый татлы икән. Җәннәт җимешләре белән сыйлаганы өчен кешеләр кызны бик яратканнар. Шуннан соң аңа «Сөмбелә – уңыш кызы» дип исем кушканнар. Сөмбелә исә, һәр елны тырыш, уңган кешеләрне мул уңыш белән шатландырган. Кешеләр дә ел саен, уңышларны җыеп алгач, кыз хөрмәтенә Сөмбелә бәйрәме үткәрә башлаганнар.

**Сабрина БИКТАШЕВА,**
**Нурлат шәһәре, 1 нче урта мәктәбенең**
**6 нчы сыйныф укучысы**



**Зәмирә ГАРИФУЛЛИНА рәсеме.**
**Балтач, Салавыч күппрофильле лицееның 3 нче сыйныф укучысы**

# КӨЗГЕ муллыкны эзләп...

*(Квест-уен)*



**Хөрмәтле «Түгәрәк уен» журналы хезмәткәрләре!**

Безнең Олы Әтнә (Әтнә районы) балалар бакчасында бүгенге көндә 206 бала тәрбияләнә, 9 төркем эшли. Ел әйләнәсендә балалар белән төрле матур чаралар уздырабыз. Мәсәлән, көзге муллыктан күргәзмә оештырдык, безнең балалар бакчасы базасында узган «Сандугачтай моңлы Тукай теле» район бәйгесендә, «Яраткан уенчыкларым», «Төсләр», «Салават күпере», «Көзге яфраклар яңгыры», «Театр» атналыкларында катнаштык.

Габдулла Тукай исемендәге Әтнә Дәүләт драма театрында да еш булабыз, чөнки алар безнең белән хезмәттәшлек итәләр.

**Зилә ШӘФИГУЛЛИНА, өлкән тәрбияче,**
**Нурия ГАЙФУЛЛИНА, тәрбияче**

*(Залда балалар утыра.)*

**Алып баручы:** Исәнмесез, балалар! Бүген безнең балалар бакчасында бәйрәм. Кунаклар киләчәк.

*(Ут сүнә һәм проектор кабына. Экранда видео: көз айлары – сентябрь, октябрь, ноябрь – күчтәнәчләр тотып балалар бакчасына таба киләләр, ләкин алар каршысына усал Чебен гөмбәсе килеп чыга һәм көзге күчтәнәчләр тутырылган кәрзинне урлап кача. Ут яна һәм залга кәефсез генә көз айлары килеп керә.)*

**Көз айлары** *(бергәләп)*: Исәнмесез балалар, бүген без сезгә кунакка көз күчтәнәчләре белән килергә уйлаган идек. Сезгә көзге табигать һәм көзге муллык турында сөйлисебез килгән иде, ләкин усал Чебен гөмбәсе күчтәнәчләребезне урлап качты. Нишләргә инде безгә хәзер?



**Алып баручы:** Балалар, без көз айларына аларның күчтәнәчләрен эзләп табарга булышабызмы?

**Балалар:** Әйе!

*(Ут сүнә, экранда Чебен гөмбәсе күренә.)*

**Чебен гөмбәсе:** Көз сезгә килмәячәк. Мин тырыштым: яшердем, качырдым, саташтырдым. Әмма мин сезгә берничә бирем калдырам, аларны үти алсагыз, күчтәнәчләрне таба алырсыз.

*(Залда ут кабына.)*

**Сентябрь:** Эх син, явыз Чебен гөмбәсе. Ярый балалар, болай булгач, көзге муллыкны эзләп юлга кузгалабызмы?

**Балалар:** Әйе.

**Сентябрь:** Чебен гөмбәсе миңа конвертта беренче биремне калдырган. Әйдәгез, ачып карыйк. Безгә табышмак чишәргә кирәк.

*Йомшак мамык,*
*Йөзә каядыр.*
*Аска төшкән саен,*
*Яңгыр киләдер.*

**Балалар:** Болыт.

**Сентябрь:** Булдырдыгыз, балалар! Ә залда безнең болыт кайда? Болыттан кечкенә генә болыт кисәге аерылып киткән. Әйдәгез, карыйк әле, анда нәрсә бар.

*(Болыт янында шар эленеп тора, ә аның эчендә бирем.)*

**Сентябрь:** Чебен гөмбәсе безгә калдырган икенче бирем – ул ел фасыллары. Дүрт



өстәлдә ел фасыллары сурәтләнгән кисмә картиналар ята. Әгәр дә шул картиналарны дөрес итеп җыйсак – бирем үтәлгән була.

*(Балалар төркемнәргә бүленеп, җәй, көз, кыш, яз фасыллары төшерелгән картиналарны җыя.)*

**Сентябрь:** Афәрин, балалар! Барлык рәсемнәр дә җыелып бетте! Ә хәзер без алдагы биремне табыйк. Аның өчен бездә әлеге вакытта нинди ел фасылы икәнен ачыкларга кирәк. Йә, кайсыгыз әйтә?

**Балалар:** Көз.

**Сентябрь:** Дөрес. Димәк, безнең бирем көз рәсеме артына яшерелгән. Табыгыз әле аны.

*(Балалар көз рәсемен әйләндереп, анда агач рәсемен табалар.)*

**Октябрь:** Алдагы маршрутыбыз агачлар янында булачак. Анда безне тагын бер бирем көтеп тора.

*(Агачлар артына яфрак-трафаретлар белән яфрак шаблоннары яшерелгән.)*

**Октябрь:** «Яфракларның өен тап» дип аталган биремдә һәр яфракның үз өен табарга кирәк.

*(Балалар 4 төркемгә бүленеп, биремне башкаралар.)*

**Октябрь:** Балалар, бу биремне дә сез уңышлы башкардыгыз. Хәзер безгә бер яфрак артыннан алдагы биремне табарга кирәк.

*(Балалар өй рәсемен табалар.)*

**Октябрь:** Димәк, киләсе маршрут безнең өй булачак. Әйдәгез, бу йорт янына килик әле.

*(Өйдән Чебен гөмбәсе килеп чыга.)*

**Чебен гөмбәсе:** Биремнәрне үти алырсыз дип уйламаган идем. Булдырдыгыз, балалар! Хәзер мин сезгә катлаулырак бирем бирәм.

**Ноябрь:** Балалар, әйдәгез конвертны ачып карыйбыз. Монда табышмаклар.

*Аркасында тик ята –*
*Берәүгә дә кирәк түгел.*
*Стенага сөяп куйсаң –*
*Өскә менү кыен түгел.*

**Балалар:** Баскыч.

**Ноябрь:** Булдырдыгыз, балалар! Димәк, сезнең юлыгыз хәзер баскычка таба булырга тиеш. Карагыз әле, баскычта алмалар эленеп тора. Әйдәгез, алмалары өзик һәм анда нәрсәләр барлыгын карыйк.

*(Алма рәсеменең арт ягында ребус. Ребусны чишеп, «Көз» җырын башкаралар.)*

**Сентябрь:** Бик матур җырладыгыз, балалар. Конвертта – соңгы бирем. Биредә сүзләр язылган, шул сүзләрдән сүзләр чылбыры төзергә кирәк.

*(Балалар «әкәм-төкәм» дигән сүзне укыйлар. Бүлмәдә зур әкәм-төкәмне (йомшак модуль) эзләп табалар. Аның эченә кәрзин белән алмалар яшерелгән була.)*

**Алып баручы:** Бу – көзге муллык кәрзине. Афәрин, балалар, сез Чебен гөмбәсенең барлык биремнәрен дә үтәп чыгып, көз нигъмәтләрен эзләп таптыгыз.

Автор фоторәсемнәре

# Алма жыябыз

Галимҗан Латыйп сүзләре
Наилә Яхина көе




Урман кырларга
Килде матур көз.
Җәй үтте диеп
Үкенмибез без.

**Кушымта:**
Без шау-гөр килеп,
Алма коябыз.
Алны тутырып,
Алма жыябыз.

Бакчада хуш ис,
Бакчада ямьле.
Берсеннән берсе
Алмалар тәмле.

**Кушымта.**

Әниләр безне:
– Булдырасыз! – ди,
– Бездән дә инде
Уздырасыз! – ди.

**Кушымта.**

Без аның саен
Шатланышабыз.
Әниләр белән
Без ярышабыз.

**Кушымта.**



# БӘРӘҢГЕ тәкәсе

**Бүген бездә кунакта – Татарстанның халык артисты Резедә ШӘРӘФИЕВА. Ул гаиләсендә буыннан-буынга сакланып килгән гореф-гадәтләр, йолалар, ризык рецептлары белән уртаклашты.**

**– Гаиләдә дүрт бала – ике кыз, ике малай үстек. Безне еш кына якын әби белән ерак әбиләргә кунакка илтеп куялар иде. Алар үзләренчә матур тәрбия бирделәр. Якын әбинең шигырьләр, бәетләр язганын хәтерлим. Балачакта күреп үскән гореф-гадәтләрне үз гаиләмдә дә сакларга тырышам. Әни пешергән ризыкларны хәзер үзем пешерәм. Көтелмәгән кунаклар килеп чыкса, безнең әни ялт кына бәрәңге тәкәсе пешерергә ярата иде. Ул тиз дә, җайлы да, тәмле дә була. Бүген журнал укучыларыбызга да шуны пешереп күрсәтәсем килә.**

***Камыр өчен:***

*200 мл җылымса су,*
*1 чәй кашыгы тоз,*
*2 аш кашыгы майонез,*
*3-4 аш кашыгы көнбагыш мае,*
*йомшак камыр килеп чыгарлык он.*

***Эчлек өчен:***

*Бәрәңге (вак итеп турыйбыз),*
*суган (күп итеп турыйбыз),*
*тоз, борыч, зирәне тәменчә салабыз,*
*теләгән кеше фарш та куша.*

## Җиде сорау

1 ***– Татар хатыны пешерә белергә тиешле өч ризык?***

– Татар хатыны, гомумән, бөтен ризыкны да пешерә белергә тиеш (көлә). Үзебезнең милли ризыкларыбыздан: гөбәдия, чәк-чәк, өчпочмакны пешерә белмәгән татар ханымнары юктыр.

2 ***– Татар ир-аты яраткан өч ризык?***

– Ирләр гадәттә итле ризыклар ярата. Кулдан кискән токмачлы, итле аш белән өчпочмактан, каз итеннән пешерелгән бәлештән ирләрнең берсе дә баш тартмас.

3 ***– Ир-ат йөрәгенә юл ашказаны аша, дигән сүз белән килешәсеңме?***

– Килешәм. Пешкән ризыкларга күңел җылыңны да кушып пешерсәң, ул тагын да тәмле була бит. Өстәле буш булган, әмма бизәнеп-ясанып утырган хатын-кызга караганда, ир-ат өстәле ризыкларга мул булган хатын-кызны сайлый.

4 ***– Балачак нинди ризык белән хәтереңә уелып калды?***

– Әни пешергән бәрәңге боламыгының тәме әле дә тел очында... Бәрәңге боламыгына әз генә он кушып, уртасына май салып бирә иде ул.

5 ***– Гастрольләрдә йөргәндә кайсы якта нинди милли ризыклар белән сыйлыйлар? Моңарчы күз күрмәгән, ят ризык ашаганың булдымы?***

– Әйе, чыннан да һәр якның үз ризыгы. Әтнә якларына кайтсаң – гөбәдия, Кукмарада – борай бәлеше, Пенза якларында урама белән сыйлыйлар. Ят ризыклардан – Бурятиягә баргач, яшел чәйгә тоз, сөт салып эчерт-



теләр. Моңарчы бер тапкыр да андый чәй эчкәнем юк иде, бик тәмле булды.

6 ***– Әгәр Резеда Шәрәфиева ресторан ачса, фирменный ризыгың нәрсә булыр иде икән?***

– Бәрәңге тәкәсе, әлбәттә!

7 ***– Француз мәкале: хатын-кыз юктан да скандал, салат һәм эшләпә ясый белә, ди. Эшләпә ясый аласыңа ышанам, ә скандал белән салат ясый алыр идеңме? Ул юктан гына ясалган салатның рецепты?***

– Эшләпәсен генә түгел, салатын да ясыйм, әмма скандалсыз гына. Өйдә булган яшелчәләрне турап, исле көнбагыш мае, тоз, борыч салып болгатам да – тәмле салат килеп чыга.




*1. Алда әйтелгән барлык ингредиентларны кушып, йомшак кына камыр басабыз. Ясагач, камырны 20 минутлап ял иттерәбез*



*2. Эчлек ясыйбыз: вак итеп бәрәңге, суган турыйбыз, фарш кушабыз (мин шулай яратам), тоз, борыч, зирә салып болгатабыз*



*3. Камырны вак кисәкләргә бүләбез. Җәеп, уртасына эчлекне салабыз*



*4. Ярымай рәвешенә китереп бөреп куябыз да, майлы табага тезә барабыз*



*5. Әзер бәрәңге тәкәләрен кайнар газ миченә куеп, 160-200 градуста 45-60 минут пешерәбез*



*6. Пешеп чыккач, бәрәңге тәкәләрен мичтән алып, өсләрен майлыйбыз. Аннары урталай кисеп, эретелгән сыер мае сибеп, табынга чыгарабыз*

***Ашларыгыз тәмле булсын!***

Дмитрий Петриченко фоторәсемнәре

# ШАХВОРД

Таблицадагы хәрефләр тезмәсеннән шахмат фигурасы – атның дөрес йөреш тәртибен кулланып, уңыш бәйрәме – Сөмбеләгә багышланган бер куплетлы шигырь укыгыз

|  | м | й | м | ң | ә | р | т | ш | и |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| р | й | У | г | е | а | ы | к | к | у |
| д | ә | ә | и | г | ә | | и | л | ә |
| з, | ө | ә | г | п | р | ә, | е | р | и |
| б | л | Н | з | л | б | б | ә. | б | г |
| к | е | е | ә | е | г | ч | С | т | к |
| ө | р | | | й | | е |  | ә | и : |
| с | з | л | г | з | з | ө | | и | е |
| а | Г | г | ә | с | е | д | н | Д | н |
| е | н | л | з, | е | г | у | с | р | е |

**Шахворд җавабы – саннарда**

Бер сан бер хәрефкә туры килә. Шигырь 93 хәрефтән тора.

|  | 19 | 16 | 37 | 2 | 21 | 56 | 39 | 4 | 23 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 17 | 36 | 1 | 20 | 81 | 38 | 3 | 22 | 57 | 40 |
| 34 | 15 | 18 | 53 | 70 | 55 | | 79 | 24 | 5 |
| 51 | 68 | 35 | 82 | 77 | 80 | 71 | 88 | 41 | 58 |
| 14 | 33 | 52 | 69 | 54 | 89 | 78 | 93 | 6 | 25 |
| 67 | 50 | 83 | 76 | 85 | 92 | 87 | 72 | 59 | 42 |
| 32 | 13 | | | 74 | | 90 |  | 26 | 7 |
| 49 | 66 | 75 | 84 | 91 | 86 | 73 | | 43 | 60 |
| 12 | 31 | 64 | 47 | 10 | 29 | 62 | 45 | 8 | 27 |
| 65 | 48 | 11 | 30 | 63 | 46 | 9 | 28 | 61 | 44 |

**Педагогия фәннәре кандидаты**
**Нәҗип ШАКИРҖАНОВ төзеде**

**Шахворд җавабы:**
Уңыш әби:
Дуслар бәйрәмгә килгәнсез,
Гөлдәй матур киенгәнсез.
Нилләр китердегез көзгә,
Сөйләп бирегезче безгә.

# Истәлекле һәм онытылмас даталар
# 2020

**3 октябрь**

Шагыйрь, педагог, галим Габдулла Бигинең (Габдулла Хәсән улы Мостакаевның) тууына 130 ел (1890-1983 елдан соң)

**7 октябрь**

Җырчы, РСФСРның атказанган, Татарстан Республикасының халык артисты Рәхилә Хәйдәр кызы Мифтахованың тууына 80 ел (1940-1999)

**10 октябрь**

Казан дәүләт консерваториясе ачылуга 75 ел (1945)

**11 октябрь**

Актриса, Татарстан Республикасының атказанган артисты Венера Мансур кызы Шакировага 60 яшь (1960)

**11 октябрь**

«Шәһри Казан» газетасы чыга башлауга 30 ел (1990)

**15 октябрь**

Кама Тамагы муниципаль районы Үзәк китапханәсе ачылуга 100 ел (1920)

**17 октябрь**

Журналист, җәмәгать эшлеклесе Роза Рәхмәтулла кызы Туфитулловага 75 яшь (1945)

**27 октябрь**

Актриса, ТАССРның атказанган артисты Роза Мөхәммәт кызы Җиһаншинага (Минзәлә театры) 90 яшь (1930)

**28 октябрь**

Әдәбият галиме, филология фәннәре кандидаты Таһир Шәмсегали улы Гыйләҗевкә 60 яшь (1960)

**28 октябрь**

Рәссам, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б. И. Урманче исемендәге премиясе лауреаты, Россия сәнгать академиясенең хәзерге заман тасвири сәнгать өлкәсендәге премиясе лауреаты Равил Габделбәшир улы Заһидуллинга 60 яшь (1960)

**29 октябрь**

Композитор, җырчы һәм музыка эшлеклесе, Башкортстан АССРның халык артисты Газиз Салих улы Әлмөхәммәтевнең тууына 125 ел (1895-1938)

**3 ноябрь**

Монументаль сәнгать рәссамы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Илдар Мәнсәви улы Хановның тууына 80 ел (1940-2013)

**8 ноябрь**

Әдәбият галиме, тәнкыйтьче һәм педагог Хәй (Габделхәй) Хисмәтулла улы Хисмәтуллинның тууына 125 ел (1895-1977)

**8 ноябрь**

Язучы, фольклорчы галим, филология фәннәре кандидаты Эдуард Салихҗан улы Касыймовның тууына 90 ел (1930-1986)

**12 ноябрь**

Журналист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Исмәгыйль Сәлман улы Шәрәфиевнең тууына 70 ел (1950-2017)

**14 ноябрь**

Композитор, курайчы, халык уен кораллары – курай, кубыз, сорнайлар – ясау остасы Ифрат Нигъмәт улы Хисамовның тууына 90 ел (1930-2000)

**14 ноябрь**

Актер һәм педагог, ТАССРның атказанган артисты, М. Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты Шамил Мәсгуть улы Бариевның тууына 70 ел (1950-1994)

**18 ноябрь**

Актриса, педагог, ТАССРның халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Наилә Хәким кызы Гәрәевага 80 яшь (1940)

**5 декабрь**

Педагог, шагыйрь һәм фольклорчы Сәхаветдин Кәшшафетдин улы Миңлекәйнең (Миңлекәев) тууына 125 ел (1895-1954)

**9 декабрь**

Шагыйрь, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Хәсән Фәхри улы Туфанның тууына 120 ел (1900-1981)

**15 декабрь**

Җырчы, Башкортстан АССРның, ТАССРның халык артисты, РСФСРның атказанган артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Фәридә Яһүдә кызы Кудашеваның тууына 100 ел (1920-2010)

**24 декабрь**

Эстрада артисты, нәфис сүз остасы, ТАССРның атказанган артисты Фәйзи Сәйяр улы Йосыповның тууына 110 ел (1910-2001)

**27 декабрь**

Рәссам Диләрә Ленар кызы Нәүрүзовага 50 яшь (1970)

(Татарстан: Истәлекле һәм онытылмас даталар календаре = Календарь знаменательных и памятных дат. 2020 – Казан: Милли китап, 2019. – 200 б.)









Кадерле укучыларыбыз!
2021 елның беренче яртыеллыгы өчен «Түгәрәк уен» альманахына республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә, яисә «Почта России» сайты аша (https://podpiska.pochta.ru Индекс ПА 183 яисә «Тугарак уен» дип җыярга) онлайн да языларга мөмкин.

Индексыбыз – ПА 183
Өч айга язылу бәясе – 182 сум 18 тиен
Ярты елга язылу бәясе – 364 сум 36 тиен

БЕРГӘ БУЛЫЙК, ДУСЛАР!